84(2Рос=Баш)
аб
М98

Рәфис Мөхәммәтдинов

# Йөрәгем тавышы

Шигырьләр

аб
84(2Рос=Баш)
М98

**Рәфис Мөхәммәтдинов**

52106 – 40523

# *Йөрәгем тавышы*

Шигырьләр

Ц Б С Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

**Тәтешле район
типографиясе
2005 ел.**

## *Үзем турында үзем*



*Мин, Мөхәммәтдинов Рәфис Нәҗип улы, 1960 елның 28 февралендә Башкортстанның Яңавыл районы Яңа Уртавыл авылында гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килгәнмен. Әткәм-әнкәм гади колхозчылар иде. «Балалы гаилә бәхетле була», -- дисәләр дә, минем авыр язмышым әткәм-әнкәмә кайгы-хәсрәт тә китергән. Тугыз аем тулып тәпи киткәч, янып торган мич плитәсенә барып тотынып пешкәннән соң, нык куркудан аякка басып йөрмәс булганмын. Әбиләргә, табибларга күрсәтеп караганнар, файдасы тимәгән.*

*Укырга, язарга өйдә генә өйрәндем, укытучылар өченче сыйныфка кадәр килеп йөрделәр. Мәктәпкә бару бәхете эләкмәде миңа, шулай да шат күңелле бала идем, туганнарым, дусларым һәрчак янымда булдылар.*

*Үсә төшкәч китаплар укый башладым, бигрәк тә шигырьләр ярата идем, бераздан үзем дә кулыма каләм алдым. Менә инде унбиш ел мәкаләләрем, шигырьләрем гәзит-журналларда басылып тора. Шатланып, канатланып эшлим, шигырьләрем күп кенә күмәк җыентыкларда дөнья күрергә өлгерде. Минем сүзләргә язылган җырлар да бар.*

*Инвалидлар коляскасында гына утырып гомер кичерсәм дә, үземне бик бәхетле саныйм. Иң зур бәхетем әнкәй, аның тәрбиясендә яшим, әткәй вафат булды. Туганнарымның, күршеләремнең, дусларымның ярдәме зур! Язмышташым, каләмдәшем, никахлы тормыш иптәшем Кәүсәриям бар. Очрашып кына яшәсәк тә, дөньябыз короллы, телефон аша көн дә хәбәрләшеп торабыз.*

*Менә аерым китабым да дөнья күрде. Аны чыгарырга ярдәм итүчеләргә рәхмәтем чиксез! Киләчәктә дә башым түбән иелмәсенә ышанам, хәлемнән килгән кадәр ялкынланып иҗат итеп яшәрмен.*

***АВТОР.***

## *Котә*

Язлар җитү белән кошлар кайта,
Кайтмый калмый алар бер ел да.
Күрше карчык капка төпләрендә,
Карашлары анын зур юлда.

Маңгаена төшкән ак чәчләрен
Яулык асларына яшерә.
Кайтмады бит, бүген дә юк, диеп,
Битен кайнар яше пешерә.

Сугыш беткәнгә дә инде биш ел,
Гомеркәйләр бик тиз үтә шул.
Яу кырында ятып калган ирен
Тугры хатын шулай көтә шул.



## *Син юк, әткәй!*

Чәчәк атты язын бакчабызда,
Әткәм, син утырткан алмагач.
Авыр икән, бигрәк авыр икән
Ир балага әткәй булмагач!

Синең киңәшләрең, ярдәмнәрең,
Синең ныклы куллар бик кирәк.
Булыр иде ң авыр язмышыма,
Исән булсаң, бүген бер терәк.

Коляскамда бакчабызга чыгам,
Чәчәк искәйләрен суларга.
Кереп кенә югалгандай булдың,
Их, әткәем, тирән суларга.

Бирешмимен, әткәй, өйрәнелде
Барчасына инде түзәргә.
Әл дә әнкәем бар яннарымда,
Пешкән алмаларны өзәргә!

* * *

Гэзиттә бер сурәт, анда сабый,
Томыраеп ла карый күземә.
Матурлыкны Ходай кызганмаган
Бу нарасыемның үзенә.
        Сурәтенең аскы өлешенә
        Ни язганнар, әллә хатамы?
        Җаны булган ана үз баласын
        Чүп савытына соң атамы?
Хата түгел, әйе, бу чынбарлык,
Вәхшилекнең җиттек чигенә.
Сабый исән, дәүләтебез карар,
Тик анасы, ахирәткә күчкәч,
Әйтер икән җавап ни генә?

## *Ямьсезлек*

Урамда икәү талаша,
Әйтелә авыр сүзләр.
Чәч-башлары тузып беткән,
Акаеп тора күзләр.
Бер-берсенә юл куймыйча
Бик озак талаштылар.
Телләре арып туктагач,
Артларын чабыштылар.
Гыйбрәт алып үтсә иде
Күпләр болар яныннан.
Алар бит ике бөртекләр
Бер ана карыныннан.

## *Тирәк*

Алларымда җил-давылга
Бөгелә бер тал-тирәк.
Бу кадәрле давылларга
Сынмый түзәргә кирәк.

Бөгелсә дә, сыгылса да,
Түзә шул, түзә тирәк.
Әйтерсең ул авырлыкны
Күп җиңгән минем йөрәк!

* * *

Берәм-берәм китәбез шул,
Мәңгелек түгел беркем.
Килер ул әҗәл дигәнең,
Мине дә алыр беркөн.

Бәлки бүген килеп алыр,
Бәлки әле күп елдан.
Тик, Ходай, соңгы көнгәчә
Аерма мине, аерма
Иманымнан, хак юлдан!

* * *

Сукмакта икмәк сыныгы,
Балчыкта аунап ята.
Авыру карчык тәрәзәдән
Моны күреп ут йота.

Тик нигәдер бу икмәккә
Берсе игътибар итми.
Иренми, иелеп алып,
Читкәрәк куеп китми.

Берәр мәрхәмәтле бәндә
Күреп алыр дип көтә.
Карчыкның күз алларыннан
Ачлык еллары үтә!

## *Озату*

Күрше егет китә армияга,
Яше җиткән инде китәргә.
Ил алдында торган зур бурычын
Намус белән, ихлас үтәргә.

Якыннары, дус-ишләре килә,
Күрше-тирә керә агылып.
Саубуллашкан чакта күңелләрдә
Шомлы уйлар китте чагылып.

Илләребез бер дә тыныч түгел,
Кан исләре аңкый җирләрдән.
Хәбәрләрнең килә каралары,
Ичкирия дигән җирләрдән.

Нинди генә хәлләр юк бу җирдә,
Уйга батып авыр сулыймын.
Ил уллары китә армияга,
Тәңеремнән: туган җирләренә
Исән кайтар, диеп сорыймын!

## *Коньякка карап уйланам*

Моңсу көздә, җанга сагыш өстәп,
Кыр казлары очты коньякка.
Күзләремне яшь пәрдәсе каплап,
Карап калдым мин дә шул якка.
Авылымның коньягында зират,
Анда әткәм, әби-бабамнар.
Озатылды инде шул якларга
Күпме дуслар, күпме туганнар!
Язын кошлар кайтыр, ә үлгәннәр
Кайта алмый инде кирегә.
Кыр казлары булып алар рухы
Кайтадыр ул, димен, бирегә!

## *Яралы күцел*

Әнкәсенә сырпалана
Нәни песи баласы.
Теле белән ялый-ялый
И иркәли анасы.
Бу күренешне күзәтә
Ымсынып ятим малай.
Аның да яратыласы
Бик тә килә бит шулай.
Әнкәсе аны тугач та
Карамый ташлап киткән.
Бу бәхеттән мәңгелеккә
Улын ул мәхрүм иткән!

## *Мин дә бәхетле*

Ак яулыклы әби үтеп бара,
Җилләр җилфердәтә яулыгын.
Карты-яше сәлам биреп уза,
Сорашалар аның саулыгын.

Авылдашлар гына түгел, хәтта
Күрше авыл таный очратып.
«Кендек әби!» — диеп эндәшәләр
Чын күңелдән аңа, яратып.

Аның ярдәмендә дөньялыкка
Тудырган бит мине әнием.
Язмышларның бәхетлесен теләп,
Кендегемне кискән әбием!

*   *   *

Илемә илле бишенче
Яз килә, Җиңү язы.
Әмма нигәдер күңелдә
Юк бер дә шатлык назы.

Ветераннар җанында да
Борчулы уйлар янә.
Самолетлар ил өстенә
Бомба ташлый бит әнә.

Чечня җирендә зур сугыш,
Күпме кеше газабы.
Кайчандыр бер бу мәхшәрнең
Булыр микән азагы?

Халкым фашистны җиңгән бит
Тынычлык булсын өчен.
Киләчәктә мәңге-мәңге
Ал таңнар тусын өчен!
Нигә сугышабыз?

## Әни

Әнисмнең чәчләренә карыйм,
Сирәк кенә калган карасы.
Маңгаенда тирән буразналар,
Күргәннәрнең ачы ярасы.
Сугыш елларында үсмер кызый
Җирен сөргән, йөргән тырмага.
Җир үлчәгән, «грамм» тараткан ул,
Печән ташыган кыш фермага.
Ачлыгын да, ялангачлыгын да,
Кайгысын да күргән гомерендә.
Яу кырыннан кайткан әти белән
Гаилә корган туган җирендә.
Саф мәхәббәт җимешләре булып,
Дөньяга биш бала килгәнбез.
Килгәнбез дә, шатлык кына түгел,
Кайгылар да өеп биргәнбез.
Сабый чакта беребез вафат булса,
Ә мин авырыйм бала чагымнан.
Нәни тәрбиясе биреп карый,
Юк авыр сүз әни ягыннан.
Безне ташлап мәңгелеккә китте
Әтием дә якты дөньядан.
Сабыр булды, бирешмәде әни,
Нур китмәде туган оядан.
Йөзләренә ап-ак чәчкәйләре
Биргән кебек үзгә матурлык.
Әнисмнең шушы яшәү юлы
Асылда бит олы батырлык!

## *Кешеме син?*

Кичә генә кеше итеп
Таный идем мин синс.
Кешелекле, тәүфыйклы, дип
Саный идем мин синс.
    Бүген «кеше» дип әйтергә
    Телем әйләнми синс.
    Бу эшең синең мәңгегә
    Тетерәндерде минс.
Күреп калгач, күз яшемә
Ирек бирдем, тыялмый.
Олы яшьтәге атаңа
Суктың бит син оялмый!

*18 август 2002 ел.*

## *Бераүгә*

Аяк-кулларың исән-сау,
Йөгереп йөрер чагың.
Артык бер адым ясарга
Авырсынасың тагын.
    Сау-сәламәт булсам үзем,
    Борчымас идем синс.
    Ходай аяк-кулларымнан
    Мәхрүм иткән шул минс.
Хәрәкәттә — бәрәкәт, ди,
Авырсынма йөрергә.
Миңа ярдәм иткән өчен,
Ходай сиңа насыйп итәр
Оҗмахларга керергә!

*30 август 2002 ел.*

* * *

Ярдәмчел иде картый,
Ачык күңелле кеше.
Мактауга гына лаек
Эшләгән барлык эше.

Дини иде картыем,
Намазларын куймады.
Кешеләрне рәнҗетмәде,
Гонаһалар җыймады.

Тугыз балага яшәү
Биргән ана иде ул.
«Хәрам белән ялганнан
Кач син, балам!» — диде ул.

Картый инде мәрхүмә,
Аны гел искә алам.
Әйткән сүзен онытмыйм,
Аңа тугры калам!

*31 гыйнвар 2005 ел.*

## *Йорәк тавышы*

Өй кыегында янәшә
Гөрли ике күк күгәрчен.
Берсен-берсе сагынышып
Кавышканнардыр, күрәсең.

Пар күгәрченнәргә карап,
Сагышлардан тулды күңел.
Без икебез ике ярда,
Бу бит һич тә дөрес түгел.

Карлы, бозлы җил-бураннар
Килеп керде араларга.
Бер ялган сүз көче җитте
Йөрәкләрне яраларга.

Бәхет өчен көрәшик без,
Бер-беребезгә без бит кирәк.
Күгәрченнәрдәй парлашып
Яшәгез, ди, безгә йөрәк!

*1-2 февраль 2005 ел.*

## *Акылыңа кил*

Карашларың нурсызланган,
Күреп торам, үкенәсең.
Әйтерсең лә, күзгә карап
Ярдәм сорап үтенәсең.

Җаным әрнеп сызланамын,
Синең хәлләреңне күреп.
Наркотикның сазлыгына
Баткансың бит тәмам кереп.

Әйтсәләр дә: «Бу сазлыктан
Чыгулары мөмкин түгел!»
Ә шулай да көч табарсың,
Син җиңәрсең ул афәтне,
Дип ышана минем күңел!

*16 июнь 2005 ел.*

* * *

Баланнар да чәчәк аткан инде,
Җәй аеның тәүге көннәре!
Төнен кырау төшеп салкынайтты,
Китеп тора коннең юньнәре.

Бозлы яңгыр явып үтте бүген,
Коеп чәчәкләрнең таҗларын.
Саклап калалмадым чәчәкләрне,
Бирсәм дә мин күңел назларын.

Әрнеп, яшьле карашларым белән
Куакларга карыйм кызганып.
Балаларын җуйган аналардай
Яшәрләр күк алар сызланып!

*15 июнь 2005 ел.*



52106 - 40523

ЦБС Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

## *Туган көнем*

Туганнарым, салкын кыш көнендә
Мондый бүләк кайдан таптыгыз.
Янып торган тере чәчәк тотып,
Бәйрәмемә минем кайттыгыз.

Бүләгегез белән бар күңелем
Дөньяларын әсир иттегез.
Сез бит миңа февраль аенда ук
Җәйләр бүләк итеп киттегез.

Беләм тере чәчәк күп тә тормый
Сулачагын минем янымда.
Сезнең хөрмәтегез бәйрәм булып
Гомерлеккә калыр җанымда.

* * *

Зурларга охшарга теләп
Бала рюмка тота.
Алар белән чәкәштереп,
Тәмле газлы су йота.

«Карале, минем дә улым
Үскән!» — дип ана көлә.
Хәзергә көләсең дә соң,
Азак еламассың микән,
Ханым, диясем килә!

## *Сәбәп*

Табын корып дус-ишләрен
Кунакка дәште бер ханым.
Ун көн элек туган көнен
Юган идек бит без аның.

Аннан кызы туган көнне
Чәкәштереп бәйрәм иттек.
Елы тулган каенатасын
Шунда искә алып үттек.

Тагын нинди бәйрәм икән,
Әллә ире туган көнме?
Бүләк алып барыйм микән,
Соң, котларга анда кемне?

Баргач күрермен әле, дип,
Конверт белән акча алдым.
Бу мәҗлесе ни сәбәпле?
Моны белгәч хәйран калдым.

Эчкелек чиреннән ире
Дәваланып чыккан кичә.
Шуны юу максатыннан
Ханым оештырган кичә!

## *Яз нуры*

Гөлләрем яшәрә ел саен,
Тәрәзәдән яз нуры кергәч тә.
Йөрәгем әллә ни эшләде,
Мин сине тәү тапкыр күргәч тә.
Ялкынлы хисләрем ташудан,
Пышылдап әйтелде сүзләрем.
Син мине кирегә какмадың,
Шатлыктан балкыды йөзләрем.
Сызланган җаныма, тәнемә
Сихәтнең бирдең син иң зурын.
Сулмасын күңелем гөлләре,
Бул минем гомерлек яз нурым!

*19 март 2001 ел.*

## *Болында*

Казлар чыкты, бәбкәләре
Яшел үлән чүпләп йөри.
Чәлдерергә бәбкәләрен
Бер тилегән читләп йөри.
Ата каз, һай, сизгер бит ул,
Тилегәнне куып китте.
Башка яктан икенчесе
Ни арада килеп җитте.
Аналары бирәме соң,
Җыеп алды канатына.
Ә мин уйлыйм ятимнәрне,
Йөрәгемнән кан атыла.

* * *

Нәни генә әле яфраклары,
Балан агачлары яшәрә.
Тагын ямьле җәйгә җитәбез бит,
Бу күренеш шуңа ишарә.

Алмагачлары да чәчәкләргә
Бөреләнеп килә күренеп.
Тузганакның сары чәчәгенә
Тирә-ягым ята төренеп.

Бакчабызга әнкәм чыгып баскан,
Моңсуланып тора күзләре.
Йөзләрендә тирән сырлар ята,
Гомеренең җиткән күзләре.

Шул мизгелдә Ходай кодрәт биреп,
Могҗизалар булса майтарып.
Әнкәйне дә гомер җәйләренә
Куяр идем янә кайтарып.

*6 май 2001 ел.*

## *Шәһәр урамыннан барганда*

Бер кардәшем әйтте бүген миңа:
«Сөйләш әле рус телендә.
Өнәмимен шушы татар телен,
Рус теле бит ул җиңел дә!»
        Аннары ул: «Гарьләндерә, — диде, —
        Авыл урамында түгелбез.
        Бөтенесе бездән көлә сыман,
        Әллә нигә шуңа күңелсез».
«Мин гарьләнмим, — дидем аңа карап, —
Горурланам татар булганга.
Гарьләнәмен бүген синең кебек
Татарлардан урыс туганга».

## *Тормыш кадерен белерме?*

Сабый гына әле үзе,
Бишектә көнкүрмеше.
Асты юешләнсә, шыңшып,
Ачыкса, елау эше.
        Дөньялыкка туганына
        Булса булыр өч атна.
        Инде чүпрәк -чапырагы
        Яннарында бер тартма.
Төрле-төрле уенчыклар
Әзер тора уйнарга.
Төпсез ыштан киеп үскән
Дәү әнисен бу күренеш
Сала моңсу уйларга.

## *Юк, башымны имәм*

Ходай миңа каты сынау биргән,
Хәрәкәтсез аяк-кулларым.
Кеше ярдәменнән тыш кабалмыйм
Авызыма тәгам суларын.

И, Ходаем, күпме каһәрләмә,
Башымны һич түбән имәмен.
Бу доньяда аяк-куллыларның
Моң-зарларын ишетүе авыр,
Мин, бәхетсез булдым, димәмен.

* * *

Җиргә кадәр бөгеп агачларны,
Җил-давыллар сыный ныклыгын.
Килдем, әткәм, тагын кабереңә,
Бигрәк сиздерә шул юклыгың.

Кулда чәчәк, шуны кабереңә
Көчем җитми үрелеп салырга.
Анда рәхәт икән, дисәләр дә,
Юк, ашыкмыйм әле барырга.

Зарланырга дип килмәдем, әткәй,
Елакларны сөймим, беләсең.
Килә минем имәннәрдәй яшәп,
Үлгәндә дә көлеп үләсем!

## ***Яшә!***

*(Кәүсәриягә).*

Ярты гасыр элек тавыш биреп,
Фани дөньяга син тугансың.
Алтын көздә тугангамы әллә,
Алтыннан да алтын булгансың.

Рәхмәтем зур сине бу дөньяга
Бүләк иткән атаң-анаңа.
Язгы ташкыннардай, йөрәгеңнән
Ургып-ургып, ярсып моң ага.

Халык өчен, һәрчак сафлык өчен
Яшәүләрең синең җан атып.
Күңелләргә ятыш иҗатыңны
Кабул итә халкым яратып.

Көтсен әле алда сине тагын
Уңышларның иң-иң зурлары.
Яшә әле, озак еллар яшә
Сибеп безгә алтын нурлары!

## *Соңгы өмет*

Читкә яшьли китеп адашканнар
Сагышлардан түгә күз яшен.
Төшләренә кереп йөди һаман
Авыл урамнары ямь-яшел.

Хәтфә үләннәрдән йөгерә-йөгерә
Каз бәбкәләр саклый балачак.
Таңнар аткач, тагын сагышлардан
Күңел мөлдерәмә тулачак.

Алар өчен сырхауларга дәва
Чишмәләрнең йотым суы да.
Бер туйганчы авыз итәр иде,
Ерагайган хәзер юлы да.

Кире кайту бүген мөмкин түгел,
Гомер калган көнләп санарга.
Ике метр җире туган якның
Соңгы өмет инде аларга.

## *Күңелем йолдызы*

Күктәге йолдыз булсаң да,
Иң яктысы булыр идең.
Күңелемнең түрләренә
Нурың белән тулар идең.
    Ала алмас идем синнән
    Карашымны төннәр буе.
    Хыялыйлар булыр идем
    Сине уйлап көннәр буе.
Бәхетемдер, син бит җирдә
Өметемнең иң яктысы.
Сүнмәс ул, мәңгелек булыр
Мәхәббәтебез чаткысы!

## *Басуда*

Карлар эреп җир-су кипкән инде,
Яшәргәннәр урман-кырларым.
Игенчеләр чыга басуларга
Тыңлый-тыңлый тургай җырларын.
    Йомшак кына язгы җилләр назлап
    Игенченең тарый чәчләрен.
    Җәй уңышлы килсен, диеп, әби
    Дога кыла иртә-кичләрен.
Игенчеләр, авыл уңганнары
Бирешмәсләр заман җиленә.
Алар кебек тырыш халкым барда
Ачлык килмәс туган илемә!

## *Сагыну*

Кичке моңнар агыла авылымда,
Яшьләр йөри гармун уйнатып.
Тәрәз читләреннән качып кына
Әбекәем кала күз атып.

Сагынадыр ул да яшь чакларын,
Күзләп кала авыл яшьләрен.
Урамнарда моң агылган чакта
Күзләрендә күрәм яшьләрен.

## *Җырың кайта*

*(Авылдашым Гайнан Әмири истәлегенә).*

Авылыңны сагынып кайта идең,
Тирәгенә кошлар кайтканда.
Кар сулары эчеп акланнарда,
Умырзая чәчәк атканда.

Авылыңны сагынып кайта идең,
Тулышканда кырда башаклар.
Күңелеңнән шигырь булып чыкты
Авылыңда йөргән шул чаклар.

Син юк инде, шагыйрь, ә авылың
Көтә һаман, мин дә сагынам.
Җылы язның сандугачы булып,
Җырың кайта туган ягыңа.

## *Хыянәт*

«Аяк-кулы берчә туңган икән,
Исән калыр микән бичара?
Яшәр инде кул-аяксыз килеш,
Күрәчәге шулдыр, ни чара!»

Сөйләүләре әле дә хак булмады,
Аяк-куллар исән, терелде.
Кәләш алып, матур гаилә корды,
Дөньялары гөлгә төренде.

Бөтенесе яхшы сыман иде,
Тагын хәбәр йөри халыкта:
«Хәләл җефетен сөяркәсе белән
Тоткан икән аулак чарлакта».

Күп тә үтми аерылышты алар,
Хак булгандыр халык сүзләре.
Күңел туңын эретер көч тапмады,
Күз алдында сулды йөзләре.

## *Эш узгач*

Гөрләп яшәр чакта алар
Һич татулык белмәде.
Урамнарга чыгып хатын,
«Катсын» диеп теләде.
    «Изалар чиктем гомергә,
    Бер рәхәт тә күрмимен.
    Җәфалауларыннан качып,
    Кемгә генә кермимен?!»
Килде ул көн, ире вафат,
Кан-яшь түгә шул ханым.
Фәрештә булган икән бит
Хәләл җефете аның!

* * *

«Миллионнар алып эшлимен,
Авыл миңа нәрсәмә.
Шәһәремдә гулять итәм,
Куллар тыгып кесәмә.
    Азык-төлек бәясе дә
    Арзан бит бездә шактый».
    Кайткан саен авылдашым
    Яшәгән җирен мактый.
«Елга бер дә кайтмас идем,
Монда әнием яши».
Киткән чакта авылдашым
Сумкаларын чак күтәрә,
Елмаеп калам, дәшми.

## *Ялгыз әби*

Ару-талуларны белми,
Җим ташый кош баласына.
Нарасые авызларын
Ачып тора анасына.
　　Гаиләләре тулы бөтен,
　　Өч баласы, ата-ана.
　　Нинди бәхетле минутлар,
　　Шатлыкларга һич юк чама.
Ялгыз әби агачтагы
Кошлар оясына бага.
Кошчыкларны күреп аның,
Сагышлардан күңеле тулып,
Күзләреннән яшьләр ага.

*　　*　　*

Елга ярсып ташса ярларыннан,
Тирә-якка чыгып тарала.
Су астында калган ялан-кырлар
Яшеллеген җуя, карала.
　　Әгәр күңел ташса, авызыннан
　　Яхшы, яман сүзләр түгелә.
　　Хак-ялганмы, кая карап тору,
　　Кызулыктан кемдер сүгелә.
Сулар агып тынгач, карайган җир
Кояш нурларында яшәрер.
Тик нахакка рәнҗетелсә кемдер,
Гомере буе күзе яшьләнер.

* * *

Авыл юллары таш, асфальт,
Сукмаклары хәтфә чирәм.
Шау чәчәктә алмагачлар,
Нурлар чәчә бөтен тирәм.

Бала-чага тавышыннан
Нур өстенә ямь өстәлә.
Тагын шуны әйтә алам,
Шигыремә мин өстәмә.

Һәрбер йортка газ, су кергән,
Каладан юк һич аерма.
Авыл сүзен ишетүгә,
Канәгатьсез йөз җыерма.

Яшьләр китми, яши алар
Туган җирнең кадерен белеп.
Болай булгач, ышанамын,
Авылым калмаячак үлеп!

## *Нишләр иде?*

Дөньядан туйдым, ди берәү,
Аск та болай үзе.
Аяк-куллары да йөри,
Исән-сау ике күзе.
Нишләр иде, зәгыйфьләнеп,
Бәндәгә бәндә калса?
Безнең кебек, мәңгелеккә
Ходай урынга салса?
Җан-тәннәребез сызлауга
Учлап дару кабабыз.
Үләсе килгән чакта да
Елмаер көч табабыз!

* * *

Җирне тырный-тырный елый,
Дәрья анын күз яше.
Өзгәләнә хатын җаны,
Дөнья куйды иптәше.
Авыл халкы чыш-пыш килә:
«Бик яшь калды бичара.
Тиңе чыкса, янә чыгар,
Табылмас башка чара».
Бер тол хатын әрнү катыш
Әйтеп куйды шул ара:
«Беренчесе булмый шул ул,
Хет миңгә барып кара».

## *К а й т у*

Челтәрләнгән инде кар өемнәр,
Яз коящы карый дөньяга.
Гөрләвекләр ага, елга таша,
Кошлар кайта туган ояга.
Канатлылар, нинди бәхетлеләр,
Туган җирдә оя яңарта!
Шатлыклары тышка бәреп чыгып,
Тирә-юньгә моңын яңгырата.
Бер бабай да кайткан туган якка,
Түбән иеп йөри башкаен.
Кире борып булса гомер угын,
Салыр иде нигез ташкаен!..

* * *

Син минсез булып,
мин синсез булып,
Моңа кадәр ничек яшәдек?
Гомер языбыз үтеп киткәнче
Бер-беребезне күреп дәшмәдек.
Ни хәл итәсең, тәкъдирләр
шулдыр,
Соң булса да бит, уң булсын, диләр.
Гомер җәебез булсын дәвамлы,
Булмасын анда кар-бозлы җилләр!
Син мине таптың, мин сине таптым,
Бәхет нурлары балкый йөзләрдә.
Авырлыкларга бөгелми-сынмый
Яшәргә язсын килер көзләрдә!

## *Төшләремә бик еш керәсең*

Төшләремә бик еш керәсең син,
Сагынуымнандыр, күрәсең.
Бүген тагын күрдем, талчыбыктан
Казларга дип оя үрәсең.

Җитез кулларыңа күз иярми,
Кем әйтәлер, уң кул зәгыйфь, дип.
Фашист ядрәсенең кайпылчыгын
Үзең белән алып киттең бит.

Исән чагында ук үзеңә дә,
Алтын куллысың син, диделәр.
Син төзегән йортта гомер итеп,
Баскан итегеңне киделәр.

Төшләремә еш керәсең, әткәй,
Әткәй, дип, их, өндә дәшәргә!
Язсын инде, берүк, синең кебек,
Дөньялыкта соңгы сулышкача
Гел изгелек кылып яшәргә!

## *Карлар ява*

Ябалаклап ап-ак карлар ява,
Тирә-юньдә шундый матурлык.
Мамыктай пакъ шушы ак карларны
Түшәк итеп кенә ятарлык.

Шушы кадәр аклык-сафлыкларга
Басарга да хәтта кыймассың.
Бәс ябынган агачларны күзләп
Гомерең буена да туймассың.

Карлар ява, ап-ак карлар ява,
Яусын, әйдә, яусын шатлыкка.
Тормыштагы булган пычраклыклар
Бетсен әле, күмелеп аклыкка!

## *Хөрмәтебез сезгә*

Хатын-кыз ул тормыш матурлыгы,
Бар дөньяның яшәү терәге.
Шушы гүзәллектән ялкын алып,
Дөрләп яна ирләр йөрәге.

Хөрмәт белән сезгә, хатын-кызлар,
Башыбызны түбән иябез.
Безнең йөрәк ялкыннарын шулай
Мәңге сүндермәгез, диябез.

## *Таркалдылар*

Тиң булмады, аерылабыз инде,
Күпме була болай түзәргә.
Балам нәни чакта ирем белән
Араны, дим, кирәк өзәргә.

Ялгызыма тормыш авыр булса,
Парын табып, бәлки, чыгармын.
Ул алкашка тынгы бирәмме соң,
Алиментын күпләп сыгармын.

Бер яшь ханым шулай, күкрәк киереп,
Тирә-юньгә чәчте зәһәрен.
Тик балама гына ата булмас,
Дип әйтмәде бер сүз «каһәрең».

Таркалдылар, бала ятим калды,
Төп сәбәбе моның — эчкелек.
Әле һаман җәмгыятебездә
Хөкем сөрә нинди көчсезлек!

## *Бәхет нуры*

Кырга чыктым август иртәсендә,
Хуш ис аңкый иркен кырларда.
Кыр-кораблар килә тезелешеп,
Штурваллар тырыш кулларда.
    Таң җилләре тулы башакларны
    Талгын гына итеп тибрәлтә.
    Тышта челлә, көннәр бигрәк бөркү,
    Игенчегә авыр, тирләтә.
Шул тир белән салган орлыклардан
Мул уңышлар җиткән өлгереп.
Күрәм, әнә, сезнең хезмәт бит ул,
Бәхет нуры тора бөркелеп.

## *Шатлык*

Ага чишмә челтер-челтер,
Яннарында таллары.
Суын алып авыз итсәң,
Яктыра күз аллары.
    Чишмә буе таллары да
    Җаннарга якын үзгә.
    Әнә, сандугач та нидер
    Әйтергә тели безгә:
«И, кешелек, туган җирдә
Синең күрер шатлыгың.
Саклап кына тор кадерләп
Талларыңның яшеллеген,
Чишмәләрнең сафлыгын!»

## *Кәүсәриягә*

Исемнәрең генә түгел,
Җисемнәрең дә әйбәт.
Синең хакта кара эчләр
Сөйләмәсеннәр гайбәт.

Күзләреңдә таң нурлары,
Кояш назы күңелендә.
Кара болытлар йөзәлмәс
Безнең сөю күгендә.

Көнчеллектән кайберәүләр
Сөйләмичә нишләсен?
Син бит минем дөньялыкта
Һәрчак кәүсәр чишмәсе.

*«Кәүсәрия» — җәннәт чишмәсе.*

## *Күл буенда*

Күл өстендә йөзә икс аккош,
Бер-берсенә янәш сыенып.
Тау артына ай да кереп китте,
Күлгә чумып чыккач коенып.

Пар аккошлар алсу таң атканчы
Тирбәлделәр назлы бишектә.
Мылтык аткан тавыш! Монсы инде
Гафу ителми берничек тә!

*8 май 2004 ел.*

## *Нигез котә*

Маһир иде әткәм бар эшкә дә,
Йорт-кураны үзе төзеде.
Матур гына яшәп яткан чакта
Гомеркәе аның өзелде.

Ихаталар инде тузып бара,
Моны күреп сызлый йөрәгем.
Капка баганасы тәмам тузган,
Вакытлыча куйдык терәвен.

Сарай түбәләре тишкәләнеп,
Эчләренә аның су киткән.
Минем хәлләремнән бер эш килми,
Ә туганнар читне үз иткән.

Ялгыз ана гына нишли ала,
Тормыш сорый ирләр кулларын.
Зур батырлык тоеп иңнәрендә,
Кайтырлар, дип, туган якларына
Атам нигезе көтә улларын!

* * *

*(Апама).*

Җәйләрнең иң җылы, кояшлы,
Чәчәкле аенда тугансың.
Әткәйгә, әнкәйгә һәм безгә
Бер генә кыз бала булгансың.

И, гомер дигәнең аккан су,
Син инде иллегә җиткәнсең.
Шул уңай, зур табын әзерләп,
Энеңнәр килгәнен көткәнсең.

Изгелек кылучы фәрештә,
Булдың син гомергә зур терәк.
Ишетче, йөрәкләр тибәләр:
Безгә бит, апам, син гел кирәк!

Гаиләңә күз генә тимәсен,
Гел шулай шатланып яшәгез.
Балалар кайгысын күрмичә,
Эшләрең уң булып, авырмый,
Бәхетле яшә, дип дәшәбез!

## *Бала күңеле далада*

Балдай татлым, дип иркәли
Ана газиз баласын.
Сизә микән ул бервакыт
Ялгыз торып каласын.

Балам, диеп күп аналар
Тәгамнәрен өзәләр.
Карт көнендә ялгыз калгач,
Дәшми алар түзәләр.

Әй балалар беләме соң
Аналарның кадерен.
Бар бит адәм актыклары,
Хәтта белми каберен.

Әйтегезче, каян килә
Бу кадәрле явызлык?
«Бүләк» итмә иде, бала,
Карт анаңа ялгызлык!

## *Килениәргә*

Кайнанасын хурлый килен
Барча таныш-белешенә.
Өйрәтә дә өйрәтә, ди,
Кысыла бөтен эшенә.

Ирек бирми үзебезчә
Бер тынычлап көн итәргә.
Әнә, кызлары чакыра,
Теләми анда китәргә.

Балалары үскән инде,
Нигә кирәк карт кайнана.
И син, килен, улларың бар,
Дип әйтәсем килә аңа!

*22 октябрь 2003 ел.*

* * *

Кычкыртып куйды бер ханым
Карт әнкәсен усал итеп.
Мин аңарга карап куйдым
Гаҗәпләнеп, исем китеп.

Балаң түгел, әнкәң бит ул,
Ничек шулай дәшмәк кирәк.
Ана җаны нишләгәндер,
Үксеп куйды минем йөрәк!

*27 декабрь 2002 ел.*

* * *

Ниләр булды безгә, халкым,
Кай тарафка барабыз?
Дингә түгел, бозыклыкка
Якыная арабыз.

Яше-карты урамнарда
Исереп, аунап ята.
Бер рюмка хәмер өчен
Күпләр иманын сата.

Намаз укып утырырлык
Әби-бабайлар эчә.
Аларның яман гадәте
Яшүсмерләргә күчә.

Эчеп, тәмәкесен тартып
Йөри бүген балалар.
Ата-аналар тыялмый,
Үзләре шул «салалар».

Яшәү болай дәвам итсә,
Эшләребез бик харап
Упкынга таба барабыз,
Кардәшләр, алга карап!

*Октябрь 2004 ел.*

*   *   *

Әллә төшем, әллә өнем минем,
Нәрсә күрәм, нәрсә ишетәм.
Ләх исереп берәү килеп керде
Көпә-көндез безнең ишектән.

Бу күренеш хәзер гадәти хәл,
Диярсездер инде, мөгаен.
И сүгенә тозлап һәм борычлап,
Егылгандыр, тишкән маңгаен.

Бу күренеш, юк шул, төшем түгел,
Мин өнемдә күрәм барсын да.
Намазлыкта гына утырасы
Карчык басып тора каршымда!

*10 декабрь 2003 ел.*

*   *   *

Әллә нинди сәер холыкым бар,
Үпкәләргә генә торам гелән.
Үпкәчелем, дисәң, назлап кына,
Син хаклысың инде, иркәм, беләм.

Синең шушы назлы сүзләреңнән
Рәхәтлеккә тула бар күңелем.
Төзәтәлмәм, ахры, бу холкымны,
Дөрес аңла зинһар мине, гөлем!

Үпкәләрмен!

*Декабрь 2003 ел.*

## *Туган көнең*

Матур булып кояш чыкты,
Таң ату белән иртән.
Бүген синең туган көнең,
Бәйрәмең белән, иркәм!

Гел кояшлы гына булсын
Алда да һәр таңнарың.
Бүләк итәм чәчәкләрнең
Зәңгәр, кызыл, алларын.

Аяз күгең болытласа,
Җилләр булып исәрмен.
Гомерең буе тормышында
Гөлләр булып үсәрмен.

Кабул ит син бар дөньяның
Нур көлтәсе бәйләмен.
Бүген синең туган көнең,
Котлы булсын бәйрәмең!

*9 ноябрь 2004 ел.*

## *Яшәүгә мәхәббәт*

Гомер җәемнең йомгагы
Акрын гына сүтелә.
Сикәлтәле тормыш юлым
Гел көрәштә үтелә.

Язмыш авыр, тешләремне
Кысып-кысып түзәмен.
Хәлләремнең авырлаша
Барганлыгын сизәмен.

Сызланулар белән үтә
Яшәлгән һәрбер көнем.
Хәлләр авырлашкан саен
Яшисем килә минем.

Шау чәчәкле, нурлы дөнья,
Килми аннан китәсем.
Көрәшеп булса да шулай
Әле гомер көземне дә
Килә минем үтәсем.

*7 ноябрь 2004 ел.*

* * *

Туган яктан үзем китмәсәм дә
Моңа кадәр әле аерылып.
Тосп торам, читтә яшәүләрс
Җинсл түгел, канат каерылып.
Туганнарым, якын дус-ишләрем,
Күпләр бүген читтә көн итә.
Күпләренең йөзләрендә сагыш,
Туган җиркәйләргә ни җитә!
И, Ходаем, туган җирләремне
Ташлап китәрләргә язмасын.
Гомеремнең калган сәгатьләре
Туган яктан читтә узмасын!

*3 ноябрь 2004 ел.*

* * *

Мәктәпкә ашыга бер ир,
Сәгатенә карап ала.
Күрәсең, ул укытучы,
Дәресенә соңга кала.
Авызында тәмәкесе
Төтсн бөркеп килә алдан.
Укучылары да бара
Аның белән бергә юлдан.
Укытучы була иде
Тәрбияче, үрнәк кеше.
Балаларга ул соң ничек:
«Тартмагыз» дип үгет бирсен,
Үзе булгач тәмәкече.

*Октябрь 2004 ел.*

* * *

Тышта нинди матур чак,
Бөтен тирә-юнь ап-ак.
Җем-җем итеп кар ява,
Сулап туйгысыз һава.
Агачларга бәс кунган,
Тәрәзләргә боз туңган.
Тауда уйный балалар,
Чана, чаңгы шуалар.
Көннәр буе уйныйлар,
Уеннан һич туймыйлар.
Куркытмый һич салкыннар,
Яшь йөрәктә ялкын бар.
Бер карт тора күзәтеп,
Яшьне булмый үзгәртеп.
Чана, чаңгылар тузган,
Егәрле чаклар узган!

*6 гыйнвар 2004 ел.*

* * *

Нәфрәтләнеп карап тордым
Тәрәз аркылы кичә.
Юл буенда ике хатын
Утырып хәмер эчә.
Тәмли алар авызларын,
Тәмәкеләр суырып.
Минем шулчак йөрәгемне
Куйды нидер куырып.
Хатын-кызлар, гүзәл затлар,
Сез бит газиз аналар.
Әйтегез, бу нишләвегез?
Сездән ямьсез үрнәк алып
Үсә бит кыз балалар!

*15 май 2005 ел.*

## *Гармун бәйрәмендә*

Яңавылда бәйрәм бүген,
Гадәти бәйрәм түгел.
Моң агыла тирә-юньгә,
Җилкенеп тора күңел.

Берсеннән-берсе остарак
Гармунчылар җыелган.
Әллә гармун телкәйләре
Алтыннардан коелган.

Бөтен республикабыздан
Килгән монда талантлар.
Бу бәйгедән күпләр алыр
Иңнәренә канатлар.

Ата-бабалардан калган
Тальян гармун моңнары.
Киләчәктә дә яңгырар
Саф чишмәдәй чыңнары.

Гармуннар күрү шатлык бит
Яшүсмерләр кулында.
Моң чишмәләре тынмасын
Һәрчак Яңавылымда.

*17 июнь 2005 ел.*

## *Без*

Тормыш юлын кулга-кул тотышып
Икәү бергә атлый алмыйбыз.
Ходай безгә нинди каты сынау
Биргәнлеген яхшы анлыйбыз.
Син дә, мин дә сабый хөкемендә,
Көн күрәбез бишек арбада.
Бер-беребезгә булган сөю хисе
Ялкын булып дөрли арада.
Язмышларны күпме каргасак та,
Җиңеләймәс инде хәлебез.
Хәлләр авыр, диеп, башны иеп,
Юк, юк, еламыйбыз әле без.
Кулыбызда каләм, икебез дә
Шагыйрь, шагыйрәләр булганбыз.
Тумаганбыз елап яшәр өчен,
Җырлап яшәр өчен туганбыз!

*16 июль 2005 ел.*

## *Кунакта*

Кунак өстәлләрен бизи
Ялт-йолт итеп шешәләр.
Төрле матур тостлар әйтеп,
Аракысын эчәләр.
Бер-берсенә бәхет, шатлык,
Исәнлекләр телиләр.
Ә чынлыкта берсен-берсе
Упкынга бит этәрәләр,
Нигә шуны белмиләр?!

*15 июль 2005 ел.*

## *Үкенмәссең микән?*

Син сукырсың бүген, саңгыраусың,
Ишетмисең кошлар сайравын.
Күрмисең син болыннарга чыгып
Якташыңның чалгы кайравын.
    Яшисең син шәһәр уртасында,
    Дус-иш белән дөнья куасың.
    Торган җирем җәннәтләргә тиң, дип,
    Күкрәгеңне каккан буласың.
Күрәм: бүген синең алларында
Җәйрәп ята «байлык» диңгезе.
Үкенмәссең микән беркөн килеп
Бетергәнгә атаң нигезен?!

* * *

Мамык түшәк өсләрендә
Сабый йоклый ташланып.
Килә аның гомер юлы
Яңа гына башланып.
    Әти-әнисе янында
    Торалар бик шат, карап.
    Шулай булмый, көттеләр ич
    Аны Ходайдан сорап.
Бәхет, ризыклары белән
Әле тагын тусыннар.
Ата, ана өчен генә
Түгел, үсеп ул балалар
Ил терәге булсыннар!

*8 гыйнвар 2001 ел.*

## *Яңа ел килә*

Бәйрәм белән! Бәйрәм белән!
Яңа ел имин килсен!
Шатлык-куанычтан һәркем
Кояштай балкып көлсен.

Кырларыбызда тагын да
Игеннәр күкрәп уңсын.
Бәхетле булып дөньяга
Күпләп сабыйлар тусын.

Төрле бәхетсезлекләрдән
Ходай, берүк, сакласын.
Кайгы-хәсрәт берәүнең дә
Ишекләрен какмасын.

Иң зур байлык — сәламәтлек,
Сау булсын бар ил халкы.
Тынычлык теләп дөньяга,
Яңа ел уты, балкы!

*26 ноябрь 2001 ел.*

## *Ана зары*

### *(Җыр)*

Тәрәзәмнән күзли-күзли
Тала ике күзем.
Өч улымнан ялгыз калдым,
Бир, Ходаем, түзем!
        Сәгатьләр көн, көннәрем ай,
        Авыр үтә вакыт.
        Хәлләремне белүче юк,
        Кайтып ишек шакып.
Эшегез күп шул, балалар,
Доньялыкта, харап!
Тотсагыз иде ичмасам
Каберемне карап!

*Карам Әхлиуллин көе.*



* * *

*(Җыр)*

Тәңкә-тәңкә карлар ява,
Кулларым иңнәрендә.
Без бәхетле пар аккоштай
Мәхәббәт илләрендә.
Нинди ләззәтле минутлар,
Йөрәктә яшьлек хисе.
Әйтерсең яз, синнән бөрки
Чәчәкләрнең хуш исе.
Сиңа төбәлгән карашым
Сабый күңеледәй керсез.
Ай, йолдызлар безгә шаһит,
Пышылдап әйтәм бер сүз.

*Алик Локманов көе.*

* * *

*(Җыр)*

Сагышларга салып китмә,
Иркәм, салкын кышларда.
Кышкы көннәр ямансу бит,
Сайрамыйлар кошлар да.
Кышкы көннәр салкын була,
Елгалар, күлләр туңа.
Китәм, дисең, еракларга,
Күңелем боек шуңа.
Бозлары киткәч елгалар
Агарлар бер агышка.
Китмә, китмә еракларга,
Салып мине сагышка.

*Урал Рәшитов көе.*

## ***Чыкмыйсың исләремнән***

***(Җыр)***

Сакат талларына барып,
Җиләкләр өзә идек.
Канатлар тоеп иңнәрдә,
Хыялда йөзә идек.
**Кушымта:**
Каен җиләге өлгергән
Сакат тау буйларында.
Исләремнән чыкканың юк,
Син генә уйларымда.

Төшләремдә күрәм бүген
Җиләкле болын ямен.
Онытalмыйм җиләктән дә
Татлы иренең тәмен.

**Кушымта.**

Бергә үткән юлларыбыз
Аерылды шул ялгыш.
Бәхетле булалмадык без,
Күрәсең, шулдыр язмыш!

**Кушымта.**

*15 июнь 2005 ел.*

## *Сокландыргыч хезмәт*

Күзләр җитте, басулардан
Җыеп алынды иген.
Игенчеләр хезмәтенә
Сокланыйк кына бүген.

Алар көнне төнгә ялгап
Эшләделәр эшләрен.
Бөртеген дә югалтмаска
Кызганмады көчләрен.

Гәрәбәдәй ашлык белән
Тулды ындыр, келәтләр.
Әйтик без игенчеләргә
Матур, изге теләкләр.

Исәнлек-саулыклар сезгә,
Бәхетегез зур булсын.
Киләчәктә дә игеннәр,
Берүк, гел шулай уңсын!

*5-6 сентябрь 2004 ел.*

## *Көтәм әле*

***(Җыр)***

Көтәм җылы, шау чәчәкле
Яңа язлар килүен.
Кояш нурларын дөньяга
Сибә-сибә көлүен.
    Көтәм әле, көтәм, көтәм
    Җылы язлар килүен.
Көтәм әле очкан кошның
Туган якка кайтуын.
Бакчадагы сиреньнәрнең
Шаулап чәчәк атуын.
    Көтәм әле, көтәм, көтәм
    Сайрар кошлар кайтуын.
Теләмимен гомерләрнең
Ялгызлыкта үтүен.
Көтәм язның икебезне
Тик бәхетле итүен.
    Көтәм әле, көтәм, көтәм
    Бәхетле яз җитүен.

*5-6 апрель 2003 ел.*

## Ышанам мин

*(Җыр)*

Давылларга каршы барам,
Талса да канатларым.
Онытылмый хәтеремнән
Сиңа биргән антларым.

Бөгелсәм дә, сыгылсам да,
Егылып калмам, дидем,
Мин сине бәхетсез итеп,
Утларга салмам, дидем.

Аямыйча өя тормыш
Авырлыкны иңнәргә.
Мәхәббәттән көч алам мин
Сынауларны җиңәргә.

Ышанамын, синең белән
Киләчәккә барырмын.
Гомерем буе антларыма
Хыянәтсез калырмын.

*19-20 апрель 2001 ел.*

*Фәнир Галимов көе.*

*　*　*

Очып-очып төшә алларыма
Тупылларның сары яфрагы.
Чәчләремнән тарап-тарап үтә
Көзге җилнең салкын тарагы.
　　Бакчадагы чәчәк-гөлләрнең дә
　　Кырау алган инде төсләрен.
　　Сине эзли күңел, сине көтә,
　　Сагыш белән тулган хисләрем.
Кыр казлары, әнә, китеп бара,
Җанда якты өмет уяна.
Кошлар язын кайта, бәлки без дә
Күрешербез дип күңел куана!

*24 сентябрь 2001 ел.*

*　*　*

Тормыш бит ул ярсыз дәрья,
Бер ялгызың йөзәсең.
Дулкыннары бәрә, кага,
Тешең кысып түзәсең.
　　Тормыш бит ул ярсыз дәрья,
　　Ялгыз ничек узарсың.
　　Дәрьяларны кичәр өчен
　　Пар канатың булып сиңа
　　Килә кулым сузасым.

## *Китмә, иркәм*

***(Җыр)***

Китәм, дисең, иркәм, китәм, дисең,
Синнән башка язлар килерме.
Язлар килер, беләм, килми калмас,
Син булмагач назын бирерме.

Язлар белән сайрар кошлар килеп
Талларына очып кунарлар.
Шул мизгелдә юксынудан минем
Күзләремә яшьләр туларлар.

Ташлап китмә, берүк, ялгыз итмә,
Безнең өчен кошлар кайтсыннар.
Язның сихри нурлы иртәләре
Тик икебез өчен атсыннар.

*Наил Шәймәрданов кое.*

## *Көт, бәгырем*

***(Җыр)***

Саубуллашу җиңел буламы соң?!
Янә калдым юллар чатында.
Кар көртләре күмде юлларыңны,
Озак йөри язган хатың да.

Төшләремдә барам яннарыңа,
Күрешергә дип сузам кулымны.
Сагынасың бит, син дә сагынасың,
Тоеп яшим синең җылыңны.

Кар-бураннар үзәкләргә үтә,
Юк, калалмам куркып кышлардан.
Көт, бәгырем, барам яннарыңа,
Очар канат алып кошлардан.

*Фәнир Галимов кое.*

* * *

Туган ягым кырларында
Эш кайнап тора бүген.
Иген унган, куанычлар
Балкыта күңел күген.

Һәр бөртеген югалтусыз
Җыеп алырга кирәк.
Күктә яңгыр болытлары
Күрсәм борчыла йөрәк.

Моны авыл уңганнары,
Игенчеләр дә аңлый.
Аяз көннең һәр сәгате
Файдаланылмый калмый.

Игенчеләр сынатмаслар,
Икмәк җыеп алыныр.
Туган илем келәтенә
Һәммәбезгә мөһим булган
Зур байлыклар салыныр!

*Август 2004 ел.*

* * *

Авыр, хәлләрем бик авыр,
Яшермим, әйтәм туры.
Насыйп миңа авырлыкның
Урал тавыдай зуры.

Кырык ел урын өстендә
Ятамын, ансат түгел.
Яшәлгән гомер эчендә
Аз әрнемәде күңел.

Тешләремне кысып түздем,
Түзәмен, җиңеп барам.
Тәнемдә дә, җанымда да
Көн дә арта бер ярам.

Яраларны бәйләүчедән
Яралаучы күберәк.
Әле дә ярый, өзелепләр
Төшми түзә бу йөрәк.

Бик авыр булса да хәлең,
Бирешмә әле, йөрәк.
Сиңа соңгы сулышкача
Җырлап яшәргә кирәк!

*26 февраль 2001 ел.*

* * *

«Мин татар! — дип күкрәк суга —
Мин татар булып калам.
Милләтемне бетермәскә
Армый-талмый көч салам.
Мин укытучы, укытам
Күп еллар татар телен.
Балаларга бирәм, ди ул,
Анам телендә белем»!
Ышаныргамы моңарга,
Шикләнеп тордым әле.
Аны тикшереп карарга
Бер план кордым әле.
Чакырмаса да, беркөнне
Моңа кунакка кердем.
Өендә буй җитеп килгән
Өч улын, кызын күрдем.
Алар белән сәламләшеп,
Куллар биреп күрештем.
Укуларыгыз ничек, дип
Сорашырга керештем.
«Хорошо!» дип җаваплады
Соравыма балалар.
Үз телләрендә шуңа да
Җавап бирмәде алар.
Менә укытучы әти,
Янымда тора үзе.
Ичмаса аның әз генә
Кызарса иде йөзе.

*17 февраль 2001 ел.*

* * *

Кибет алдында бер төркем
Яшь кызлар басып тора.
Тәмәкесен пошкыталар,
Голт-голт йоталар сыра.
    Тәмли-тәмли сүгенәләр,
    Исергәннәр үзләре.
    Ямьсезләнеп, сулып калган
    Чәчәк кебек йөзләре.
Алар булачак аналар,
Киләчәкнең терәге.
Яшь кызларга карап торам,
Әрнеп-әрнеп йөрәгем.

*19-20 май 2002 ел.*

* * *

Нинди тавыш килә икән, дисәм,
Күрше йортта икән «тамаша».
Авыр сүзләр әйтеп анасына,
Буй җиткергән кызы талаша.
    Анасының үгет-нәсихәте
    Ярамаган икән кызына.
    Мин бит сиңа бала-чага түгел,
    Өйрәтмә, дип, кызы тузына.
Их, кыз бала, кызулыгың белән
Рәнҗетәсең анаң күңелен.
Шуны бел син, ана үгетләре
Безгә һич тә артык түгелен.
Үзең дә бит ана булачаксың!..

*6 май 2002 ел.*

## *Ходай биргән гомер*

Кеше гомерләре төрлечә шул,
Кемдер яши йөзгә җиткәнче.
Кемдер китә ирен читләреннән
Анасының сөте кипкәнче.
Сатып ала торган әйбер түгел,
Акча төртеп, меңләп, капчыклап.
Кемгә күпме гомер әләгәсен
Ходай куйган ди бит ачыклап.
Күпме бирсә шуңа ризалашыйк,
Өлешләргә тигән көмеше.
Булган гомерләрдә дөньялыкта
Булып калсак иде тик кеше!

*14 март 2002 ел.*

* * *

Яңа гына яуган яшь карларга
Салмак кына басып атлыйсың.
Карашларың моңсу, җаннарыңа
Беркайда да урын тапмыйсың.
Кашларыңа, керфегеңә куна
Күбәләктәй очып кар-мамык.
Әллә көлеп, әллә кызганудан,
Сиңа баккан кебек бар халык.
Гомер юлларыңны үткән чакта
Бәхетеңне эзләп син таптың.
Ул бәхетең кеше яры иде,
Шуңа микән, бик тиз югалттың.

*12 гыйнвар 2002 ел.*

* * *

Сез булганга җирдә яшәү
Дәвам итә, хатын-кызлар.
Сүнми, балкып-балкып яна
Тормыш учагында кузлар.

Сездә болын чәчәгенең
Хуш исләре, матурлыгы.
Ихлас әйтәм, сокланырлык
Күпләрегез батырлыгы.

Сез булганга һәркөн саен
Табыныбыз тәмле ашлы.
Кигәнебез чиста-пөхтә,
Көннәребез гел кояшлы.

Гомер буе булыгыз сез
Безнең өчен гүзәл хатын.
Без, ирләргә, яшәү көче
Бирә сезнең кайнар ялкын!

*7 март 2002 ел.*

## *Яшисем килә*

Бер авыру үлеп китте,
Озак урында ятып.
Фани дөньяның газабын
Ярыйсы гына татып.
    Ишеткәч моны берәүләр:
    Мескен, котылган, диде.
    Караучыларына да бит
    Бигрәк авыр иде.
Мин дә урын өстендәмен,
Җиңелдән түгел язмыш.
Яшисем килә, мин үлгәч:
Котылган бу бичара, дип,
Әйтә күрмәгез ялгыш!

*3 апрель 2002 ел.*

* * *

Гомеренең яңа гына
Бөреләнеп килгән чагы.
Үсмер егет ләх исереп
Кайтып бара әнә тагы.
    Әнә шундыйларны күреп
    Борчыла шул минем җаным.
    Киләчәктә күрерменме
    Чәчәк аткан чагын аның.
Чәчәкләрен сулдырмыйча
Яшәргә көч табалырмы.
Дөньялыкта азаккача
Кеше булып калалырмы!?

*11 гыйнвар 2002 ел.*

## *Нәнәмнең бишек җыры*

Чәчләренә инде кырау төшкән,
Нәнәм кергән гомер көзенә.
Оныгының балаларын сөя
Утыртып ул бүген тезенә.

Җырлый-җырлый бишек тирбәтә ул
Безне бәвелдергән көйләргә.
Һич онытмый безгә сөйләгәндәй
Матур әкиятләр сөйләргә.

Гади әкиятләр сөйләми ул,
Эчтәлеге аның зур була.
Нәнәемнең бишек җырларыннан
Өебезгә сихри моң тула.

Шушы монда күпме мәгьнә ята,
Гел яхшыга өндәү күренә.
Хәзер генә, үсеп буй җиткергәч,
Төшендем мин шуның серенә.

*31 март 2002 ел.*

## Әрнү

Һәркемгә дә газиз булгандыр ул
Үзе туып-үскән җирләре.
Якын миңа сулар саф һавасы,
Якын миңа искән җилләре.
      Тәмле суын эчеп туеп булмый,
      Эчкән саен килә эчәсең.
      Сокландыргыч табигатен күреп,
      Күңелеңнән рәхәт кичәсең.
Тукта, тукта, ләкин кешеләрнең
Битарафлары да була бит.
Пычраталар алар табигатьне,
Җаным әрни минем шуңа бик!

*3 сентябрь 2002 ел.*

* * *

Әллә нигә мин үземне
Көрәшче дип хис итәм.
Гомерем буе авырып,
Тормыш юлымны үтәм.
      Һәр яшәлгән көннәремне
      Бер бәйгегә тиңлим мин.
      Авыр язмыш көн-төн сыный,
      Бил бирмәскә телим мин.
Көрәшәм әле, көрәшәм
Булганда рухи көчем.
Тумый бит ирләр дөньяга
Хур булып яшәр өчен!

*3-7 апрель 2003 ел.*

## *Мин табигать кочагында*

Җәйнең иң гүзәл мизгеле,
Килә татлы бал исләре.
Гүя язгы ташкын инде,
Ургый күңелем хисләре.

Бер ягымда шаулы урман,
Бер ягымда иген кыры.
Бал кортлары безелдәшә,
Ишетелә кошлар җыры.

Табигатьнең хозурлыгы
Коендыра җанны назга.
Коляскамда китеп барам,
Онытылып мин беразга.

Авыр булса да язмышым,
Юк, бирешми, тибә йөрәк.
Туган якның табигате
Яшәүгә көч бирә, димәк!

*5 сентябрь 2002 ел.*

* * *

Кабер казырга кычкырып
Дәштеләр таң аткан чакта.
Шулай дәшү бабамнардан
Калган гадәт безнең якта.

Ирләр җыелып зиратка
Кабер казырга киттеләр.
Авылдашлар бер мәрхүмне
Хөрмәтләп гүргә илттеләр.

Еракларда яшәлсә дә,
Туган җиргә кайталар шул!
Авылымда җирләгез, дип,
Соңгы сүзен әйтәлгән ул.

Миңа да килер соңгы көн,
Мәңгелек түгелмен, беләм.
Шунысы бар, туган җирдә
Яшимен мин бәхет белән.

*5-7 апрель 2003 ел.*

* * *

Көтмәгәндә хәбәр булды,
Хәбәрнең дә карасы.
Югалтты ялгыз бер ана
Йөрәккәе парәсен.

Ана җаны тетрәнеп,
Гүя упкынга очты.
Бераздан гына уянып,
Кире күзләрен ачты.

Өзелгәндәй булды анын
Йөрәгенең бар кылы.
Җиңә алырмы, ди, күпләр,
Зур кайгысын бу юлы!

Улыкае, бердәнбере
Кара гүргә керәчәк.
Синнән качып буламы соң,
И, күрәчәк, күрәчәк.

*30 гыйнвар 2003 ел.*

## *Буранлы көн*

Көннәр көйсезләнеп тора,
Котыра гына буран.
Тәрәзәмнән моңсу гына
Карап, күзәтеп торам.

Ак бураннар тәрәзәгә
Сырый ап-ак карларын.
Эчләремнән түгелергә
Тора күңел зарларым.

Авырлаша бара хәлем,
Көн саен, сәгать саен.
Яшисем килә, яшәргә
Төрлечә эзлим җаен.

Аяк-кулсыз яшәүләре
Газап ул, җиңел түгел.
Шулай да, язмыш буранын
Җиңеп, якты киләчәккә
Ашкына минем күңел!

*Декабрь.*

* * *

Буә елгасыннан бозлар китә,
Ташып чыккан сулар ярлардан.
Умырзаялар да борын төрткән
Җир ачылган төштә карлардан.

Тирәкләр дә инде бөреләнә,
Кайткан, әнә, күчмә кошлар да.
Аларга да җиңел булмагандыр
Чит җирләрдә озын кышларда.

Яз җилләре сыйпый чәчләремнән,
Кояш үбә биттән яратып.
Тау башлары ак яулыгын салган,
Иңнәренә чәчен таратып.

Буә елгасыннан бозлар киткәч,
Бар табигать китәр терелеп.
Ялан-кырлар, урман-болыннарым
Чәчәкләргә калыр төренеп.

Буәләргә ятып сулар эчә
Яр читендә үскән тирәге.
Бу бит минем туган ягым, диеп,
Горурланып тибә йөрәгем.

*8 апрель 2001 ел.*

## *Яшик*

Туу булгач, була үлем дә,
Син дә, мин дә берчак китәрбез.
Туган җирнең кара туфрагын без
Мәңгелеккә түшәк итәрбез.
    Мин китәрмен микән синнән алда,
    Син китәрсең микән, билгесез.
    Син ничек тә, иркәм, ташлап китмә,
    Яшәү ямен күрмәм мин синсез.
Илһамланып шигырь-җыр язабыз,
Язмыш авыр, дими, көрәшеп.
Мин дә китмим әле, шулай бергә
Яшик инне-иңгә терәшеп!

*8-11 февраль 2003 ел.*

* * *

Кеше күңеле ватылырга торган
Пыяладай гына, шундый юка.
Авыр сүзләр әйтеп бер-беребезне
Рәнҗетешмик әле, зинһар, юкка.
    Бер ягымлы итеп дәшсә кемдер,
    Җан тулыша сихри рәхәтлеккә.
    Бер-береңә мәрхәмәтле булу
    Илтә безне сихәтлеккә.
Олыларга олы итеп дәшик,
Кечеләргә булыйкчы без кече.
Тел байлыгы булу кешелекнең
Бәяләнми торган бик зур көче!

*24 ноябрь 2003 ел.*

## *Хастаханәдә*

Күзем төште яшь ханымга,
Чибәрнең дә чибәре.
Бер күрүдә шул сылуга
Гашыйк булдым карт тәре.

Карчыгымнан бизде җаным,
Гел шуны уйлап торам.
Аулакта күрергә теләп,
Төрле планнар корам.

Теләгемне әйттем моңа,
Очыраттым да көчкә.
Үлсәм дә үкенмәм, дидем,
Кабул итсәң бер кичкә!

Татлы-татлы сүзләр сөйләп,
Телләрем талгач кына.
Риза булды, пенсиямне
Алдына салгач кына.

Кабул булды бугай теләк,
Керермен инде гүргә.
Хастаханәгә эләктем,
Юлыгып хәтәр чиргә.

*23-24 сентябрь 2001 ел.*

* * *

Бер авылдаш килеп керде,
Әзрәк салып алган.
Бугазын кашый: «Юкмы, – ди, –
Шешә төбендә калган?

Энем, сине туганнан да
Кадерлерәк күрәм бит.
Киләчәктә бәхилләрмен,
Зинһар өчен ярдәм ит!»

Кызганып бирдем бер ярты,
Сөенеп чыгып китте.
Тагын да эчәргә сорап,
Өч көннән килеп җитте.

Төсе качкан, үләм бит, ди,
Хәле кызганыч харап.
Даруга тоткан спиртны
Аңа эчердем кабат.

Аннары тагын килсә дә,
Салып бирә алмадым.
Авылдашның туя торган
Түгеллеген аңладым.

Канәгатьсез генә кире
Борылып чыгып китте.
Башка чакта керү түгел,
Очрашсак та бу «туганым»
Сәлам дә бирми үтте.

## *Бүген бәйрәм*

Борынгыдан калган матур йола,
Сабантуйга әйбер җыялар.
Яшь киленнәр чиккән сөлгеләрне
Колгаларга бәйләп куялар.

Бәйрәм бүген, гармун тавышларын
Ишетүдән күпләр моңая.
Киленнәрнең сөлгеләрен күреп,
Авыр сулап чибәр әби әйтте:
«Их, яшьлегем язы, син кая?»

Әйтеп куйды шулчак чибәр бабай,
Күкрәгендә ярсып йөрәге:
«Беркемгә дә һич тә бил бирмәдем,
Булдым һәрчак мәйдан терәге!»

Борынгыдан калган матур йола,
Колгаларга әйбер бәйлиләр.
Кыңгыраулар чыңлап дугаларда,
Сабантуйга безне әйдиләр!

## *Түгелсен яшь*

Колак булгач, ишетәсең,
Әйтәләр авыр сүзләр.
Шул сәбәпле көтмәгәндә
Яшьләнә кайчак күзләр.
Ир-егеткә яшь күрсәтү
Килешкән эш түгел дә.
Кара болытлар куерып
Куйгалый шул күгемдә.
Төннәр бус үксеп яттым,
Менә тагын бүген дә.
Түгелсен, әйдә, яшьләрем,
Ул кешегә булган ачу
Яшәмәсен күңелемдә.

* * *

Сорамыйм синнән, сорамыйм,
Ник боек, дип, күңелең?
Беләм бит, болай да беләм
Сиңа җиңел түгелен.
Язлар җитте, йомшак җилләр
Җиргә ятып кар ашый.
Гөрләвекләр агып төшеп,
Елга, чишмәләр ташый.
Туган ягын сагынып кайтып
Кошлар бит оя ясый.
Талпынып ла үз ягыңа
Синең йөрәгең ярсый.

* * *

Алмагачлар шау чәчәктә,
Чәчәк саен бал корты.
Авыл урамында йөрим,
Нур бөрки һәрбер йорты.

Якын миңа һәр күренеш,
Сәкеләрдә әбиләр.
Сәлам биреп кала сиңа
Монда хәтта бәбиләр.

Әнә, урам буйлап килә
Арба җиккән бер юртак.
Авылында шатлыгың да,
Кайгың да синең уртак.

Алмагачлар шау чәчәктә,
Хуш исләре таралган.
Юк, китәсем килми синнән,
Минем җаным авыл өчен
Дөньялыкка яралган.

## *Авылыма*

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Кояш илем минем, гөл илем.
Синдә тудым, синдә гомер итәм,
Назлап-назлап сөя таң җилең.

Кайгыларым, шатлыкларым синдә,
Мәгълүм аның сиңа барчасы.
Тирә-якларында елга-күлләр,
Урман, таулар, җимеш бакчасы.

Исемең дә җисемеңә килә,
Яңарасың, авылым, көн саен.
Сине ташлап читкә киткәннәр дә
Эзли кире кайтыр бер җаен.

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Колачың киң, әйдә, кайтсыннар.
Хаталарын аңлап, кире кайтып,
Бәхетләрен синдә тапсыннар!

## *Авылым турында*

Яшәрә Яңа Уртавыл,
Төзекләнә елдан-ел.
Көнкүрешләре яхшыра,
Бара дөрес юлдан ул.

Авылымда әледән-әле
Яшь парлар гаилә кора.
Сабыйларның шат авазы
Җанга дәрт өстәп тора.

Халкым уңган, иген игә,
Мал асырый тырышып.
Әзерне көтеп ятмыйлар,
Хөкүмәтне орышып.

Азан тавышын ишетеп,
Туңган бәгырьләр эри.
Иман кайта, намазларга
Үсмер малайлар йөри.

Вузларда укучыларын
Ышанып көтә авыл.
Ышанычлы өмет белән
Киләчәккә атлап бара
Безнең Яңа Уртавыл!

*30 гыйнвар 2004 ел.*

### *Бала күңеленең әрнүе*

Ана кулында стакан,
Калтырап тора кулы.
Каршында, әни, эчмә, дип,
Ялвара аның улы.
　　Әтием дә юк бит минем,
　　Килми синсез каласым.
　　Булган бөтен акчага да
　　Син аракы аласың.
Өстемдәге кисмнәрем
Таушалып-тузып беткән.
Авызыма җылы, тәмле
Ризык капкан юк күптән.
　　Минем дә бит тамагыма
　　Килә тәмле ашыйсым.
　　Өйдән соңгы икмәкне дә
　　Закускага ташыйсың.
Сатып эчтең йорт җиһазын,
Ни максатка ирештең.
Инде соңгы ризыкларны
Ташырга бит керештең.
　　Хәзер синең эчкәнеңне
　　Мәктәптә дә беләләр.
　　Озын телле сыйныфташлар,
　　Әнә, алкаш малае, дип,
　　Бармак төртеп көләләр.
Гел бишлегә укый идем,
Хәзер өчлеләр алам.
Ач булгач укыйсым килми,
Дәрескә соңга калам.

Минем балачак елларым
Бер шатлык күрми уза.
Мәктәпкә киеп барырга
Соңгы итек тә туза.
Син эчмәгәндә, әнием,
Кайгысыз үткән көнем.
Инде минем юктыр хәзер
Еламый калган төнем.
Беләм елау егетләргә
Килешкән эш түгелен.
Шомлы уйлар килеп кереп
Тетрәнә шул күңелем.
Әни, синең исереклек
Мине харап итәчәк.
Мин бик куркам, авыр тормыш
Явызлыкка, ә аннары
Тоткынлыкка илтәчәк.
Аракыны илтеп түк син
Юынтык чиләгенә.
Бүтән авызыңа капма,
Риза бул теләгемә.
Бу коточкыч яман чирдән
Син котылырга тырыш.
Көтсен безне киләчәктә
Гел якты, матур тормыш.
Бу баланың теләгенә
Кушыла бар балалар.
Аларның җан тетрәндергеч
Авазын ишетсен идс
Эчә торган аналар!

*Гыйнвар 2004 ел.*

## *Уйланам*

Сакат тавыннан күренә
Яңавыл дигән кала.
Барган саен Яңавылым
Йөрәгемә дәрт сала.

Көнләп түгел, әйтерсең лә
Сәгатьләп үсә бара.
Элеккс баткак урамнар
Асфальт бүген кап-кара.

Үсеп чыга катлы-катлы
Мәһабәт торак йортлар.
Эчләренә барып керсәң,
Бар монда бөтен шартлар.

Төзелгән яңа кибетләр,
Мәктәпләр, хастаханә.
Безгә иман нуры бирсп
Мәчет утыра әнә.

Картлар йорты да төзелгән,
Кирпечтән, ике катлы.
Бу изгс эшләрс өчен
Күпләр рәхмәткә хаклы.

Урамнары яшеллеккә
Төренгән, әнә, күрәм.
Яңавылым һәрчак данлы
Эшсөяр халкы белән.

Мин авылда! Бу тормышны
Күзәтәм хәйран калып.
Авыллар да яши хәзер
Каладан үрнәк алып.

Бүген балкып чәчәк ата
Авылыбыз, калабыз.
Заманалар авыр, диеп,
Ни күреп зарланабыз?

## *Рәхмәт*

Очар кошмы әллә бүген үзем,
Шатлыгымнан канат кагынам.
Дөньялыкта бүген тик бер ходай,
Ул син, иркәм, сиңа табынам.

Йөзләреңнән балкый үзгә бер нур,
Яннарында синең и рәхәт.
Җаннарыма биргән җылың өчен,
Мәхәббәтем, сиңа мең рәхмәт.

## *Чәчәкле яз килде*

Кояш и кыздыра, ак кардан
Ачыла туган як кырлары.
Колакта көн буе яңгырый
Кошларның иң моңлы җырлары.

Тирәкләр чәчәккә төренде,
Һавада бал корты тавышы.
Күңелгә үзгә бер ямь өсти
Чишмәләр, елгалар агышы.

Чәчәкле яз килде авылга,
Яшәрде кырларда арышлар.
Якташлар чәчүгә төштеләр,
Сынатмас, алар бик тырышлар.

Ышанам, бүген дә ышанам,
Сүзләрем чыгачак хак булып.
Уңышлы, хәерле җәй килсен,
Яшәрбез кайгысыз, шат булып.

*25-26 апрель 2001 ел.*

## *Казлар китә*

Кыр казлары китә, кыр казлары,
Көньякларга таба тезелеп.
Агачларның сары яфраклары
Салмак кына төшә өзелеп.
    Тәлгәш-тәлгәш булып янып тора
    Бакчаларда миләш, баланнар.
    Исән генә барып җитсен кошлар,
    Исән-имин яшик калганнар.
Казлар китә туган җирләреннән,
Илләр тыныч түгел чагында.
Ямьле язлар җитеп очрашулар
Насыйп итсен, берүк, тагын да.

*3 октябрь 2001 ел.*

## *Кышкы ямь*

Тәрәзләргә чәчәк төшергәндәй,
Бизәк-бизәк булып боз туңган.
Урманнарга табан карап торам,
Агачларга ап-ак бәс кунган.
    Кышкы кояш якты нурын сибә
    Туган авылымның өстенә.
    Янып торган миләш, баланнарның
    И сокланып багам төсенә.
Туң җимешләр төсен генә түгел,
Югалтмаган хәтта тәмнәрен.
Йолдызлардай җем-җем карлар ява,
Биреп көнгә үзгә ямьнәрен.

*7 гыйнвар 2004 ел.*

* * *

Җәйнең нинди матур мәле,
Җиләк-җимеш пешкән чак.
Авыл халкы чалгы кайрый,
Печәннәргә төшкән чак.

Якташларым печән чаба
Тезелешеп болында.
Чалгылары җырлап кына
Эшли алар кулында.

Юкәләр дә чәчәк аткан,
Аңкыла бал исләре.
Җиләкләп чәй эчкән чакта
Балкый күңел хисләре.

Һавасы саф, кошлар сайрый,
Җәйнең иң матур чагы.
Гел үзенә тартып тора
Табигатьнең кочагы.

И минем туган ягым!..

*18 июнь 2004 ел.*

## *К ө ч с е з*

Хата эш эшләп ташлагач,
Юньсез, дип какты башын.
Үкенде, нишләдем, диеп,
Җыерып ике кашын.

Эшләмәм мондый хатаны,
Үтсә монысы имин.
Сүзендә торалмый торган
Ир-егет түгел ич мин!

Сизмәде, беркем белмәде
Көн артыннан көн үтте.
Бу юлы нишләр, ул тагын
Таныш юлыннан китте.

*18 март 2001 ел.*

## *Моңсуланма*

Күзләр җитте, диеп, моңсуланма,
Көннәр салкын, нурсыз булса да.
Башың имә син яраткан гөлләр
Бакчаларда күптән сулса да.

Күзләр җитте, диеп, моңсуланма,
Көт, назларым белән килермен.
Сөюемнең тере чәчәкләрен
Яз гөлләре итеп бирермен.

Әй коела агач яфраклары,
Сагыш өсти-өсти җаннарга.
Мин ашкынып зур юлларга чыгам,
Тоткарлансам, тырыш аңларга.

*1993-2000 еллар.*

## *Якташларга*

Печән осте җитте, авылыбызда
Эшнең кайнап торган чаклары.
Иртән иртүк халык эшкә башлый,
Кипмәс борын үлән чыклары.

Чыклы үлән әйбәт киселә шул,
Яхшы белә халкым бу хакта.
Мәтрүшкәле чәйләр кайнап чыга
Төш җитүгә кызу учакта.

Шифалы чәй эчеп җибәрүгә,
Көч-хәл кереп китә тагын да.
Юкә агачлары чәчәк аткан,
Татлы һава тирә-ягымда.

Нинди ямьле, нинди гүзәл мизгел,
Чалгы җырлый-чыңлый як-якта.
Халкым, сезнең тырышлыкны күреп
Сокланмыйм соң ничек шул хакта?!

*10-12 июль 2001 ел.*

## *Ял көнендә*

Бүген шимбә, табигатькә
Агыла гына халык.
Китәләр алар буш түгел,
Ашау-эчүләр алып.

Су буйлары, болынлыклар
Шау-гөр килеп торачак.
Кемдер анда учак ягар,
Кемдер шалаш корачак.

Теләгән кеше кояшта
Кызынып, су керәчәк.
Болын чәчәкләрен өзеп,
Бер-берсенә бирәчәк.

Кемдер балык тотар өчен
Бүәгә аулар салыр.
Каен агачын сындырып,
Кемнәрдер миллек алыр.

Җырлап-биеп, күңел ачып
Алар рәхәтлек алыр.
Гадәти хәл, артларыннан
Чүп-чарга баткан табигать
Күпләргә рәнҗеп калыр!

*1-2 июль.*

## *Хәйран калдым*

Быел шомырт уңган икән,
Чиләкләп ташый халык.
Мин дә бардым шомыртлыкка,
Утырам хәйран калып.

Колясскамда утырам мин,
Тирә-ягымны күзләп.
Берәр төзек, исән агач
Күрерменме дип, эзләп.

Агачларның ботакларын
Сындырып бетергәннәр.
Шомырт җыеп табигатькә
Зур зыян китергәннәр.

Язлар җитсә ак чәчәккә
Төренә иде агач.
Янә кайчан җимеш бирер,
Бирерме болай булгач.

Бу акыллы кешеләрнең
Эшләгән эшемени.
Табигатьне рәнҗеткәннәр
Дөньяда кешемени.

*8-9 июль 2004 ел.*

## *Шәһәрдән кайткан бер егеткә*

Авыл кызы, диеп кимсетмә син,
Авыл кызын белеп җитмисең.
Ахрысы син болын чәчәгенең
Матурлыгын күреп бетмисең.
      Чәчәкләрнең алар хозурлыгын,
      Хуш исләрен җыйган үзенә.
      Сандугачлар моңын ишетерсең,
      Колак салсаң кызлар сүзенә.
Тырыш, тыйнак, уңганлыгы белән
Таң калдыра авыл кызлары.
Туң йөрәкне түгел, хәтта ташны
Эретерлек күңел назлары.

*3 декабрь 2001 ел.*

## *Көтмә*

Төннәр буе керфек какмый чыктың,
Тәрәзәдән айны күзәтеп.
Мөлдерәмә күз яшьләрең акты,
Хаталарны булмый төзәтеп!
      Нәфесеңә хуҗа була алмый,
      Шайтан коткыларын тыңладың.
      Син хыянәт иттең саф сөюгә,
      Яшьләреңне түкмә, соңладың.
Сөйгән кешең хәзер башкаларның
Ләззәтендә яшәр исереп.
Көтмә инде, кайтыр, диеп, көтмә,
Хыянәтне булмый кичереп!

*20 декабрь 2001 ел.*

## *Тәрбия*

Өстәлдән икмәк сыныгын
Алып идәнгә атты.
Аннары аны типкәләп,
Үзенчә уен тапты.
Баласына карап торган
Әнисе әйтте шулчак:
Болай булгач, минем улым
Зур футболчы булачак!
Икмәкне идәндә күреп,
Бабасы иелеп алды.
Ә әнисе кайнатага
Бик усал караш салды.
Аннан ярсып-ярсып әйтте:
Яшәмим монда бүтән.
Ким күрәсең бит баламны
Вак-төяк шундый чүптән!
Өй эчендә котырынды
Сафура бураннары.
Төйнәлде кием-салымнар,
Түшәк һәм юрганнары.
Картның улы да хатыны
Сүзенә колак салды.
Сиксәнгә җиткән әтисе
Босгып ялгыз калды.
Килә бу ханымга карап
Елыйсы да, көләсе.
Зур футболчы булгач улы
Үзләрен дә туп итмәсме,
Шуны килә беләсе!

*9 гыйнвар 2001 ел.*

## *Нотык*

Ата кеше унбиш яшьлек
Улын дәшеп янына.
Киңәш бирергә кереште,
Сендер, диеп, аңына.

Ата-анаңа һәрвакыт
Бул игелекле бала.
Үз гаебең үзең таны,
Кешегә якма яла.

Олыларны олы ит син,
Кечеләрне кече ит.
Яхшы кешеләргә сыен,
Яманнардан качып кит.

Хәмер, наркотик, тәмәке
Булсын һәрчак дошманың.
Дәрәҗәле, зур кеше бул,
Илгә таралсын Даның.

Бу минем сиңа тост-теләк,
Тот, рюмкаңны, улым.
Шуның өчен берне тотыйк,
Ак булсын тормыш юлың!

*15 гыйнвар 2001 ел.*

## *Теләгем*

Бакчабызда яңгырый моң
Җилкендереп йөрәкне.
Сандугачлар кайткан икән
Сагынып яшь тирәкне.

Моң агыла, аһәңле моң,
Чиртеп күңел кылларын.
Хәтерләтеп гомеребезнең
Истәлекле елларын.

Без дә, иркәм, синең белән
Вәгъдә бирешкән кичтә.
Сайрый иде пар сандугач,
Исләрдән чыкмый һич тә.

Авырлыкларга бирешми,
Килмичә авыр сүзгә.
Тагын озак-озак еллар
Сандугачлар кебек җырлап
Яшәргә язсын безгә!

*13 апрель 2001 ел.*

## *Мондый үрнәк күрсәтмик*

Табигатьне чиста саклыйк!
Телдә бары тик шулар.
Ни аяныч, көннән-көн бит
Пычрана җирләр, сулар.
Тәрәзәдән күрәм, күршем
Чүп чыгарып түкте әнә.
Юл читендә чүп-чар күреп
Өзгәләнә күңел янә.
Күрәм анда шау-гөр килеп
Уйнап йөргән балаларны.
Алар моны күреп торып
Яхшы үрнәк алалармы?!

*30 июнь 2004 ел.*

* * *

Авызында тәмәкесе,
Төпчеге генә калган.
И һаман тәмләп суыра,
Ахрысы,бераз салган.
Җитмәде, тагын кабызды,
Бөркелә төтеннәре.
Агулы төтеннәр йотып,
Бетеп бара өннәре.
Буылыплар йөткерә ул,
Йөзендә сырлар арта.
Газраил бугазыннан
Алганын белми микәнни,
Тарта бит, һаман тарта!

*14 апрель 2001 ел.*

## *Каенлыкта*

Миллеккә каен кисәләр
Җәйнең ямьле чагында.
Каеннарның кызганмыйлар
Эрессен дә, вагын да.

Һәркөн саен каенлыктан
Кисеп миллек ташыйлар.
Болыннарга артларыннан
Чүп-чарларын ташлыйлар.

Әнә берәү миллек бәйли,
Агачын төптән кисеп.
Нечкә генә әле каен,
Өлгермәгән дә үсеп.

Бу адәмнең матурлыкка
Күңелкәе тар икән.
Гомерендә бер төп каен
Утыртканы бар микән?!

*7-11 июль 2004 ел.*

## *Гармун моңы*

Кич җиттеме, әткәй гармун
Уйный иде утырып.
Өй эчләрен, күңелебезне
Саф моңнарга тутырып.

Кул эшләре эшли-эшли
Әнкәй җыр суза иде.
Әнә шулай кичләребез
Җыр-моңда уза иде.

Бүген гармун тынып калган,
Әткәй юк уйнатырга.
Абыйлар да уйный белми
Күңелне юатырга.

Мин үзем дә авырумын,
Гармун тартыр көчем юк.
Әткәйле, гармунлы чакны
Сагынмаган кичем юк.

*3 февраль 2004 ел.*

## Үз фикерем

Башкорт җирендә татарлар
Яши, имеш, изелеп.
Шундый гайбәтләр ишетсәм,
Йөрәк сызлый өзелеп.

Татар, башкорт дуслыгына
Нигә кара ягарга!
Бездәй тату милләтләрне
Кирәк әле табарга!

Башкортстан татары мин,
Яшим Башкорт илендә.
Язам, укыйм, сөйләшәмен
Үз милләтем телендә.

Ике милләт арасында
Итмәгезче сатулык.
Ата-бабалардан килгән
Безнең дуслык, татулык!

*Апрель 2004 ел.*

* * *

«Кара икмәк ашамыйм мин,
Яратам агын.
Яратам, – ди Гөлсем, – аның
Тик яңа чагын».

Икмәк сыныкларын җыеп,
Чүпкә ташлады.
Күзәп торган күрше әби,
Җаны әрнүенә түзми,
Сөйли башлады:

«И, балам, телем икмәккә
Мохтаҗ чак булды.
Ачлык-ялангачлыклардан
Йөзебез сулды.

Абзаң яуда, ике балам
Ачка шешенде.
Каһәр суккан фашист безне
Шуңа төшерде.

Ничек түзсен ана җаны,
Сорашып чыктым.
Барып кердем берәүләргә,
Өй эче тып-тын.

Өстәл өстендә ак калач,
Савытта ит, май.
Хуҗа хатын ашый тәмләп,
Утыра бик җай.

Юри генә дә дәшмәде
Минс табынга.
Куып чыгарды орышып,
Бирми кабым да.

Кемнәргә генә кермәдем,
Шакып ишекләр.
Кемнәр генә рәнҗетмәде
Шунда ничекләр!

Ә шулай да, күп очрадым
Яхшы кешеләр.
Үз авызыннан өзеп бирде
Анаң ишеләр.

Ач булсагыз да үзегез,
Юмарт иде шул.
Ярты капчык арыш онын
Бүлеп бирде ул.

Инде балаларым исән
Калмаслар дисәм.
Шушы оннан икмәк салып,
Калдык без исән!»

Ачлык елларын сөйләде
Бу әби һаман.
Гөлсем йөзен читкә борды
Оялып аннан!

## *Юл буенда чардуган*

Юл буена ук куелган
Тимердән бер чардуган.
Аңлашыла, бу урында
Зур бәхетсезлек булган.
    Кемнәрнеңдер газизенең
    Гомерләре өзелгән.
    Чардуган эчендә таш бар,
    Шундый сүзләр тезелгән:
«Башыма җитте эчкелек,
Руль артында эчмәгез.
Гомерегезне кызганыгыз,
Минем хәлгә төшмәгез!»
    Юл буенда чардуганнар,
    Искәртү ясый алар.
    Фаҗигасез булсын өчен
    Һәрвакыт безнең юллар.

* * *

Бер ирне кулга алдылар
Кыйнаганга анасын.
Актык көче белән торып
Култамгасын куя ана
Коткарырга баласын.
Оныклар бар! Ана белә
Улының да киләчәктә
Үз хәлендә каласын!

## *Авылдашым китте*

Күкрәк киереп бер егеткәй
Әйтте басып каршымда:
«Мин авылдан китәм, – диде, —
Ташлап бүген барсын да.

Эшләсәм ким-хур булмамын,
Мин ялкау егет түгел.
Кечкенәдән зур шәһәргә
Тартылып тора күңел».

Авылдашым киткәч тойдым,
Гаепледәй үземне.
Ник әйтмәдем йөрәгемнән
Чыккан шушы сүземне:

«Яшьлегендә туган яктан
Китүләре җиңел дә.
Туган җирнең туфрагы да
Алтын-көмешләрдән кыйммәт
Көчең беткәч иңендә!»

## *Көзге җыр*

Тәлгәш-тәлгәш балан җимешләре
Тирбәлдереп сыга ботагын.
Күбәләкләр булып яфрак оча,
Көз аена кердек, күр, тагын!

Алтын көздә, иркәм, очраштык без,
Якынайды шулчак арабыз.
Яфрак бураннарын ера-ера
Инде бүген бергә барабыз.

Тәлгәш-тәлгәш балан ачыларын
Күп тапкырлар авыз итәрбез.
Икәү бергә чакта бирешмәбез,
Гомеребезнең мул уңышлы булыр
Көзләренә барып җитәрбез.

## *Борчылам*

Карашларын төбәп ераkларга,
Басып тора кабер янында.
Битләреннән кайнар яше ага,
Олы кайгы ана җанында.

Газиз улын, әнә, кайтарганнар
Әйләндереп кара күмергә.
Башларына төшкән кайгылары
Онытырлык түгел гомергә.

Харап кына була япь-яшь җаннар
Чәчәк атып килгән чагында.
Бу мәгънәсез Чечня сугышлары
Күпме дәвам итәр тагын да?

Үсеп житте энем, озакламый
Солдат хезмәтенә барасы.
Тетрәндерә мине, тетрәндерә
Бу ананың ачы ярасы.

*13-15 август 2001 ел.*

*  *  *

Мин үскәч сугышка барам,
Акча эшләп кайтырга.
Түшкә орден, медаль тагып,
Әйләнермен батырга.

Минем дустымның абыйсы
Чечняда булып кайткан.
Ишеттем аның үзеннән,
Йөзләп «бандит»ны аткан.

Кайту белән өй төзеткән,
Машина сатып алган.
Әле шулай да акчасы
Үзенә бераз калган.

Дәртләнеп сөйли боларны
Күршедәге бер малай.
Киләчәк ниләр күрсәтер,
Дөньялар барса шулай!

*13 гыйнвар 2002 ел.*

## *Чишмә буенда*

Былбыллар сайрый талларда,
Авыл таңнарын ямьләп.
Чишмә буйларына төшеп,
Суларын эчәм тәмләп.

Тау астында ага чишмә,
Таштан улак куелган.
Кендек каннарыбыз аның
Суы белән юылган.

Бу чишмәдән сулар алып
Эчкән ата-бабалар.
Әле булса күпләр суын
Бик яратып кабалар.

Авылымның ничә буын
Яшь киленен күргән ул.
Һәммәсенә бәхет теләп,
Фатыйхасын биргән ул.

Хәзер өйгә торбалардан
Килгәнгә эчәр сулар.
Бетеп килә чишмәбезгә
Салынган сукмак-юллар.

Чишмә буйларын чүп баскан,
Нишләп беркем карамый?
Бу бәгырьсезлеккә, дуслар,
Юл куярга ярамый.

*28 июнь 2004 ел.*

## *Күңел күрлеге*

Тышта салкын кыш булса да,
Өебез җылы, ямьле.
Әнкәм мичкә икмәк салган,
Исләре шундый тәмле.
Тәрәз пыялаларының
Бозлары эреп төшә.
Җаннарга рәхәтлек биреп,
Кабарып икмәк пешә.
Ак оннардан пешкән икмәк
Тәмле, туклыклы булган.
Маңгай тирен түгә-түгә
Шул икмәкне үстерүче
Авылдашларым уңган!

*13-15 гыйнвар 2002 ел.*

## *Тагын бер ятим*

Сабый елый шомлы аваз салып,
Ниләр булган, ачмы тамагы?
Берәр җире әллә авыртамы,
Ябылып та тормый яңагы.
Яннарында кеше юктыр дисәң,
Алай түгел, өйдә анасы.
Тамагы да тук бит, асты коры,
Нигә елый анның баласы?
Юксынамы әллә Чечняларда
Хезмәт иткән газиз атасын.
Сизгән икән сабый озакламый
Атасының кургаш табутларда
Туган җирләренә кайтасын.

*6 декабрь 2001 ел.*

## *Ике кошчык*

Юлдан үтеп бара ике малай,
Бертуганнар алар, игезәк.
Бер-берсенә шундый охшаганнар,
Күлмәкләре дә пар, гел бизәк.

Йөрешләре дә нык охшаш инде,
Буйлары да бигрәк бертигез.
Әмма карашлары моңсурак,
Шулай булмый, моңа бар нигез.

Әти-әниләре исән килеш
Балалар бит ятим калганнар.
Авылдашлар шушы ятимнәрне
Тәрбияләргә дип алганнар.

Читтән килгән ике кошчык алар,
Чит ояда җылы алалар.
Бәхет тапсын иде киләчәктә
Авылыбызда шушы балалар.

*15 август 2001 ел.*

## *Минем бәхетем*

Алларымда йомшак мамык сыман,
Җир генәем, җәйрәп ятасың.
Өсләреңдә яланаяк йөгереп,
Килә минем тәкмәч атасым.

Кырларыңа чәчеп үстерәлмим
Бодай, арпа, борчак, арышын.
Бу бәхеттән мине мәхрүм иткән
Каһәр төшкән ачы язмышым.

Кушучыма алып, туфраккаем,
Исни алмыйм татлы исеңне.
Бәхетем шунда: җирем, җырларымда
Кабатлыймын синең исемеңне!

## *Ялгыз ана*

Картлык дигәннәрең шатлык түгел,
Сызланасың, юньләп күрмисең.
Шул хәлдә дә, ана, балам, диеп,
Кич утырып йоннар эрлисең.

Бәйлисең син җылы оекбашлар,
Бияләйләр, мамык башлыклар.
Балаларың, оныкларың тәнен
Алар салкыннардан ышыклар.

Балаларың читтә, сирәк кайта,
Зур болындай йортта ялгызың.
Туган авылкаен әллә нигә
Үз итмәде инде ул-кызың.

Син бәйләгән оек-бияләйләр
Алар тәнен җылы йөретер.
Ялгызлыктан, ана, бозга туңган
Күңелеңне кемнәр эретер?!

*   *   *

Коляскама килеп тотынды да,
Мескен, диде исерек бер бәндә.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә әйтте:
Күрми яшисең бит бер ямь дә.

Җирәнгечтәй йөзен күрмәс өчен,
Карашымны бордым читкәрәк.
Хәтерем калып аның кылыгына,
Ачу белән әйттем: Ни кирәк?

Көчкә-көчкә аягына басып,
Яктан-якка китте сугылып.
Ерак баралмады, юл читенә,
Пычыракка төште егылып.

И бичара, дидем көлемсерәп,
Син мескен дә түгел, аяклы.
Син исерек, миндә аек акыл,
Кем мескен соң монда, кем хаклы?!

## *Юлга чыгам*

Ап - ак карлар яуган кышкы кичтә
Сиңа барам, сине сагынып.
Алларымда очкан энҗеләрдән
Күзкәйләрем китә чагылып.
Алларымда дистә чакрымнар,
Ә мин һаман сиңа омтылам.
Күз алдыма килеп басасың да,
Татлы хыялларда онытылам.
Юлга чыгам, юллар шундый ерак,
Чакрымнарны саныйм кайчакта.
Ә шулай да талчыгулар кая,
Сагынып көтәр кешең бар чакта?!

## *Каз өмәсендә*

Көзге муллык, көзге байлык,
Авылда каз өмәсе.
Кызлар килә каз йолкырга,
Шат күңелле һәммәсе.
Кызлар килә каз йолкырга,
Балкып тора йөзләре.
Кулларына күз иярми,
Бигрәк җитез үзләре.
И, авылым, читкә китеп
Югалмасын кызларың.
Ямь китмәсен, ел да үссен
Оя-оя казларың.

## *Яңа ел иртәсе*

Җемелдәшеп сибелә ап - ак карлар,
Нинди гүзәл мәле ак кышның.
Урамнарга чыксам саф һавасын
Туя алмый сулыйм мин тышның.
    Тыш һавасы җанга шундый рәхәт,
    Тын юллары китә киңәеп.
    Сәлам бирә, әнә, тупыллар да,
    Колачларын миңа киң җәеп.
Бөтерелеп яуган мамык карлар
Үбеп - үбеп үтә битемнән.
Әйтерсең лә шушы минутларда
Бәхетлерәк беркем юк миннән.
    Җемелдәшеп сибелә ап-ак карлар,
    Онытылдым кереп аклыкка.
    Яңа елның һәр сәгатен, көнен
    Юрауларым бары шатлыкка!

## *Китмә, әнкәй!*

Шешенгән күз кабакларың,
Авырыйсыңмы әллә, әнкәм?
Синнән калса соң я нишләр
Канат астындагы бәбкәң?
        Болай да бит ачы язмыш
        Аз туңдырмый җаннарымны.
        Син булганга гына җырлап
        Каршылыймын таңнарымны.
Авырмас сөякләр булмый,
Авырсаң да терел, китмә.
Әнкәм, минс канатланып
Яшәвемнән мәхрүм итмә!

*   *   *

Тәрәзәмә таш аталар,
Ваталар пыяласын.
Беләләр останың килеп
Янәдән куяласын.
        Күңелемә таш аталар,
        Беләләр уаласын.
        Нинди оста куяр икән
        Күңелем пыяласын?!

## *Ялгыз калгач*

Инеш буе бүген моңга чумган,
Тирәкләрдә җырлый сандугач.
Әнкәем дә килгән монда бүген,
Чәчәк кенә чагын сагынгач.
Очраткан ул тәүге мәхәббәттен,
Кер чайкаган чакта басмада.
Шул көн әткәй ат эчерә төшкән,
Йөгәннәрен бизәп тасмага.
Кер чайкыйлар кызлар, ә егетләр
Ат эчерә, тарап ялларын.
Моңсу гына әнкәм күзләп тора,
Куяр урын тапмый җаннарын.

## *Шатлык*

Ага чишмә челтер-челтер,
Яннарында таллары.
Суын алып авыз итсәң,
Яктыра күз аллары.
Чишмә буе таллары да
Җаннарга якын үзгә.
Әнә, сандугач та нидер
Әйтергә тели безгә:
«И, кешелек, туган җирдә
Синең күрер шатлыгың.
Саклап кына тот кадерләп,
Талларыңның яшеллеген,
Чишмәләрнең сафлыгын!»

## *Горурланам*

Башка җирләрдә дә шулай микән,
Синдә юк бит, авылым, юк нәрсә!
Килгәннәр дә кабат кире китми,
Безнең якны килеп бер күрсә.

Синдә урман, елга, күлләр, таулар,
Мул уңышлы иген кырлары.
Тирәктәге сандугачларның да
Үзгә сыман монда җырлары.

Ниләр генә үсми туфрагында,
Карлыганы, алма, җиләге.
Бөрлегәннән кайта сылу кызлар,
Кулларында күздәй чиләге.

Чишмәләрең синең искиткеч саф,
Буә елгаң нинди балыклы!
Байлыгыңны күреп горурланам,
Син, авылым, уңган халыклы!

## *Чакыр мине*

*(Җыр)*

Чакыр мине яннарыңа,
Йөгереп барыйм әле.
Күзләреңә бер туйганчы
Тутырып карыйм әле.
        Чакыр мине яннарыңа,
        Ачып олы капкаңны.
        Мәхәббәт ул бер могҗиза,
        Югалтмыйкчы тапканны.
Күзләреңә бер тутырып
Туйганчы карыйм инде.
Яннарыңда җаннарыма
Бер рәхәт алыйм инде.

*Рамил Мөхәммәдиев көе.*

* * *

Ничек кенә аны мәсхәрәләп,
Тукмаганнар, канын койганнар.
Алалмагач җанын, кулларыннан
Түшәмнәргә асып куйганнар.
        Максатына ирешмәгәч дошман,
        Күзе тонып тәмам котырган.
        Утлы кисәү баскан тәннәренә,
        Җанын исә бозга катырган.
Имгәнмәгән җире калмаса да,
Бу михнәттән исән чыгалган.
Ләкин илгә кайткач аны бер сүз
Мәңгелеккә сугып егалган:
Әсир!

## *Гомер телим*
*(Җыр)*

Тәрәз төпләрендә гөлләр үсә,
Чәчәкләрнең төсе төрлечә.
Үсәр идемени алар шулай,
Әнкәй, синең кулың тимичә!
Көн дә сулар сибеп, тәрбияләп
Үстерәсең саклап, кадерләп.
Кошлар кебек үсеп таралышкан
Нарасыйларыңны хәтерләп.
Туган нигездәге гүзәллекнең
Чикләмәсен Ходай көннәрен.
Озак еллар, тагын озак еллар
Чәчәк атсын, әнкәй, гөлләрең!

*Фәнир Галимов көе.*

## *Иртәнге җыр*

Бакча арты яшел болын,
Ак чәчәккә төренгән.
Талларында кошлар сайрый,
Челтерәп ага чишмәләре,
Бар тереклек терелгән.
Очып уйный күбәләкләр,
Гүзәллеккә гүзәллек.
Җәйге иртә, мин бит гашыйк,
Сиңа гашыйк, хәлләрем юк
Җырламыйча түзәрлек.

## *Гашыйк егет җыры*

*(Җыр)*

Авылымның урамнарын
Басты көрт бураннары.
Бер күрүдә гашыйк булдым,
Шулдыр тиң булганнары.
    Көн дә, көн дә килеп тора
    Яннарыңа барасым.
    Кайнар хисләр тоташтыра
    Ике авыл арасын.

Ничекләр якынайтасы
Чакырымнар арасын.
Мәхәббәтнең көче җитәр
Табарга бер чарасын.
    Көн дә, көн дә килеп тора
    Яннарыңа барасым.
    Кайнар хисләр тоташтыра
    Ике авыл арасын.

Очып кына барыр идем,
Кош юллары булыр тар.
Бөгелеп төшмә, көт, бәгырем,
Сагынып килер кешең бар.
    Көн дә, көн дә килеп тора
    Яннарыңа барасым.
    Кайнар сөю тоташтыра
    Ике йөрәк арасын.

*Әнис Шәймәрданов көе.*

## Килер язлар бар әле

Күзләр житте, сары яфрак коя
Яр буенда үскән бөрлегән.
Су өстендә пар аккошлар йөзә,
Ялгыз итмә мине, бергенәм!
Көз салкыны булып, берүк кенә,
Йөрәгемне итмә яралы.
Бөрлегәннәр янә бөреләнер,
Безнең килер язлар бар әле.

## Туган җирдә калыйк
*(Җыр)*

Яшьлек юләрлегең белән
Канат тоясың ində.
Очам, дисең, чит җирләргә,
Кошларга карап син дә.
Кошлар вакытлыча китә,
Кайта алар яз җиткәч.
Сагынсаң да, кайтулары
Читендер ул бер киткәч.
Әйләнеп тә кайтулар бар,
Тик оя тузган була.
Дәрт булса да, дәрман калмый,
Яшь гомер узган була.
Кошлар китә, янә кайтыр
Язын оя яңартып.
Яшик әле читкә түгел,
Туган җиргә җан атып.

*Энис Шәймәрданов көе.*

## *Кышкы кичтә*

*(Җыр)*

Кышкы кичтә чык син урамнарга,
Һавалардан энҗе коела.
Ап-ак карлар җәйге күбәләкләр
Очып уйнагандай тоела.
Кышкы кичтә авыл урамнары
Сихри ямьгә, моңга күмелә.
Туй күлмәге кигән агачлар да
Җырлагандай була күңелгә.
Ямьле кичтә бергә булыйк әле,
Әйдә, иркәм, әйдә урамга.
Тормыш юлларыннан янәш атлап,
Каршы барыйк салкын буранга.

*Фәнир Галимов көе.*

## *Язгы җыр*

Мартның беренче көненнән
Яз төсе керде көнгә.
Күзем төшеп, хәйран калдым
Тәрәз төптәге гөлгә.
Кичә генә юк иде бит,
Чәчәк аткан бүгенгә.
Гөлне күреп соклanудан
Нидер булды күңелгә.
Йөрәк хисләрен тыялмый,
Кошлардай кагыну бу!
Инде кабатланмый торган
Яшьлекне сагыну бу!

## *Син мине ярат әле*

*(Җыр)*

Якты Аем, Йолдызым бул,
Кояш булып көл әле.
Сандугачын көтә күңел,
Язлар булып кил әле.

Сандугачлы язларымның
Матурлыгын күр әле.
Өзеп биргән гөлләремне
Чәчләреңә үр әле.

Ал таңнарның нуры булып,
Иркәләп уят әле.
Әллә ни булды җаныма,
Күңелемне уят әле.

Тирбәлдереп назларында,
Кайгымны тарат әле,
Яктыртып күз алларымны,
Дөньяга карат әле,
Син мине ярат әле.

*Зиннур Мөхәммәтдинов,*
*Нур Даутов көе.*

## *Әнкәйгә*

*(Җыр)*

Мин бәхетле, бик бәхетле,
Әнкәм янында бүген.
Яктырта иң назлы кояш
Күңелем зәңгәр күген.
Тәрәз саен шау чәчәктә
Җәен, кышын гөлләрем.
Син булганда гына, әнкәм,
Якты минем көннәрем!
Әнкәй, чәчең ап-ак болыт,
Карашларың таң нуры.
Син бит җирдә минем өчен
Бәхетемнең иң зуры!

*Карам Әһлиуллин көе.*

## *Чәчәк бүләк итәм*

Язгы чәчәкләрне бүләк итеп,
Кулларыңа бирдем сак кына.
Безнең күңел шомырт чәчәгедәй
Булсын әле шулай ак кына.
Шул аклыкның кадерләрен белеп,
Саклый күр син, иркәм, сак кына.
Язлар да бит гөлләр белән матур,
Сөюебез булсын саф кына.
Шомырт җимешенең каралыгы
Тапламасын хисләр аклыгын.
Син минеке, мин синеке мәңге,
Тоеп яшик сөю шатлыгын.

## *Урамым*

Зур да түгел безнең урам,
Бик бәләкәй дә түгел.
Егермс өч шәхси йорт бар,
Шуңа канәгать күңел.
Капка-коймалар буяулы,
Йортлары төзек, яңа.
Данлы якташ шагыйребез *
Исемен бирдек аңа.
Торбадан килә суы да,
Һәр йортка газы кергән.
Бу рәхәтлекне моңача
Юк иде әле күргән.
Юлларга асфальт түшәлгән,
Сукмагы хәтфә чирәм.
Шау чәчәкләргә төренә
Урамым, бар як тирәм.
Халкы да уңган, бик матур,
Хезмәт итә тырышып.
Бер-берсеннән гаеп эзләп
Йөремиләр, орышып.
Урамыбыз пөхтә, якты,
Коелган гүя нурдан.
Бәләкәй булса соң, булсын,
Алтын да булмый зурдан.

*12 апрель 2001 ел.*

* *Гайнан Әмири.*

## *Таш бәгырь*

Ана газиз улын көтеп,
Ничәмә таңнар ата.
Шахтер егет — аның улы,
Күп еллар ташлар вата.

Ялгыз ана яшен түгеп
Йота соңгы ашларын.
Ник ватмады соң ул егет
Бәгырькәе ташларын?!

*   *   *

И, туган җир, синдә генә
Бөтен күргән матурлык.
Туфрагың да синең мамык,
Түшәк итеп ятарлык.

Чишмәләрнең тәмле суын
Туя белми йотарлык.
Тәлгәш-тәлгәш җимешләрең
Тел очында тотарлык.

Үзгә синең кояшың да,
Үзгә сулар һавасы!
И, туган як, туган авыл,
Синдә йөрәк дәвасы!
Тик еракка киткәннәрне
Кире сиңа кайтарырга
Нинди чара табасы?!

## *Бер аңлармы?*

Тоткынлыкта бер кош күрсәм,
Тетрәнеп куя җаным.
Яктан-якка бәргәләнә,
Очасы килә аның.

Читлектә түгел , иректә
Яшисе килә аның.
Читлек ясаучы таш бәгырь
Бер аңлармы кош җанын?!

## *Беләсезме?*

Әй, малайлар, исегезгә
Төшәме туган яклар.
Яз кошларга оя куеп,
Гөрләвек куган чаклар.

Исегезгә төшә микән
Шау чәчәкле болыннар.
Шул болында бергә үскән
Шаян җитез колыннар.

Шул колыннар булды безнең
Атланып чапкан атлар.
Исләремнән чыкмый һаман,
Сагындыра шул чаклар.
Беләсезме, шул чакларны
Саклый тик туган яклар.

## *Егетлек!*

Бәрде-какты, типкәләде
Җаннарымны ачы язмыш.
Мескен, диеп әйтмәгез лә,
Күзгә карап, берүк, ялгыш.

Орынса да тормыш-давыл,
Үтәлмәде тамырыма.
Мин ышанам азаккача
Егет булып калырыма!

## *Татлыдан да татлы*

Йөрәк җырым, сандугачым,
Моңлы сабантургаем.
Дип атасам аны, дускай,
Ялгышмамдыр, мөгаен.

Алтын-көмешләрдән затлы,
Юкә балыннан татлы.
Дип атасам аны, дускай,
Юк, ялгышмам, мин хаклы.

Кояш нурыдай назлы да,
Анам күңеледәй аклы.
Дип атасам Туган телне,
Әллә түгел мин хаклы?!

## *Шигырь язам*

Чыккан саен авыл урамына,
Тәү күргәндәй карыйм дөньяга.
Баласына җим ташыган коштай,
Илһам алып кайтам ояга.

Чишмә суларыдай, күкрәгемнән
Ташып чыга минем хисләрем.
Әрсмә дә якын, дип җырласам,
Һич китмәсен, кешем, исләрең.

Мин гашыйкмын айлы кичләремә,
Сызылып аткан алсу таңыма.
Бәхетле мин синдә, каләмемне
Манып язам йөрәк каныма.

* * *

Талгын гына җилләр исә,
Син, шул җилләр булам, дисең.
Ач күңелең ишекләрен,
Гел наз булып тулам, дисең.

Бел, болай да син янымда
Мәңге сулмас бер чәчәгем.
Бул җилем, бул гөлем, булма
Тик давыллы киләчәгем.

## *Тере чишмә*

Салкын чишмә ага челтер-челтер ,
Бозлар аны каплый алмаган.
И, бураным, тукта, котырынма –
Кар кермәгән бер җир калмаган.

Ә бураным һаман котырына,
Ярый әле чишмәм туңмаган!
Бу дөньяда чишмә сукаедай
Татлы ризыккаем булмаган!

Ага чишмә, ага челтер-челтер,
Матурлыгын күреп куанам.
Тере чишмә кебек бит ул күңел,
Туңып кына калыр чакларымда
Якты өмет белән юанам.

## *Шигъри хат*

Авылымның гүзәллеген күреп,
Читкә киткәннәрне кызганам.
Шулар арасында туганнар бар,
Әллә шуңа бигрәк сызланам.

Җәйге кичтә чыгам урамнарга,
Чишмәләрнең чыңын ишстеп.
Сандугачлар, әнә, безгә җырлый,
Үзләренә күрә иш итеп.

Талгын гына йомшак җилләр исә,
Авыл һавасына назланам.
Сез тоймыйсыз шушы рәхәтлекне,
Туганнарым, шуңа сызланам.

Кунак булып кына авылларга
Кайтасыз да, кире китәсез.
Кире киткән булып җаныгызны
Шатлыклардан мәхрүм итәсез.



Ц В С Янаульского
района Баш. АССР
абонемент
52106 – 40523

# Эчтәлек

Котә...3
Син юк, әткәй!...4
«Гәзиттә бер сурәт, анда сабый...»...5
Ямьсезле...6
Тирәк...7
«Сукмакта икмәк сыныгы...»...8
Озату...9
Коньякка карап уйланам...10
Яралы күңел...10
Мин дә бәхетле...11
«Илемә илле биш̦енче»...12
Әни...13
Кешеме син?...14
Берәүгә...14
«Ярдәмчел иде картый...»...15
Йорәк тавышы...16
Акылыңа кил...17
«Балаш̦ар да чәчәк аткан инде...»...17
Туган җирем...18
«Зурларга охшарга теләп»...18
Сәбәп...19
Яз нуры...20
Болында...20
«Нәни генә әле яфраклары...»...21
Шәһәр урамыннан барганда...22
Тормыш кадерен беләрме?...22
Юк, башымны имәм...23
«Җиргә кадәр бөгеп агачларны»...23
Яшә!...24
Соңгы өмет...25
Күңелем йолдызы...26
Басуда...26
Сагыну...27
Җырың кайта...27
Хыянәт...28
Эш узгач...29
«Миллионнар алып эшлимен...»...29
Ялгыз әби...30
«Елга ярсып таша ярларыннан...»...30
«Авыл юллары таш, асфальт...»...31
Нишләр иде?...32
«Җирне тырный-тырный елый...»...32
Кайту...33
«Син минсез булып, мин синсез булып,»...33
Төшләремә бик еш керәсең...34
Карлар ява...35
Хөрмәтебез сезгә...35
Таркалдылар...36
Бәхет нуры...37
Шатлык...37
Кәүсәриягә...38
Күл буенда...38
Нигез котә...39
«Җәйләрнең иң җылы, кояшлы...»...40
Бала күңеле далада...41
Киленнәргә...42
«Кычкыртып куйды бер ханым»...42

«Нилəр булды безгə, халкым...» ....................43
«Əллə төшем, əллə өнем минем...» ....................44
«Əллə нинди сəер холыкым бар...» ....................44
Туган көнең ....................45
Яшəүгə мəхəббəт ....................46
«Туган яктан үзем китмəсəм дə» ....................47
«Мəктəпкə ашыга бер ир...» ....................47
«Тышта нинди матур чак...» ....................48
«Нəфрəтлəнеп карап тордым» ....................48
Гармун бəйрəмендə ....................49
Без ....................50
Кунакта ....................50
Үкенмəссең микəн? ....................51
«Мамык түшəк өслəрендə» ....................51
Яңа ел килə ....................52
Ана зары ....................53
«Сагышларга салып китмə...» ....................53
«Тəңкə-тəңкə карлар ява...» ....................54
Чыкмыйсың исләремнән ....................55
Сокландыргыч хезмəт ....................56
Көтəм əле ....................57
Ышанам мин ....................58
«Очып-очып төшə алларыма» ....................59
«Тормыш бит ул ярсыз дəрья...» ....................59
Китмə, иркəм ....................60
Кот, бəгырем ....................60
«Туган ягым кырларында» ....................61
«Авыр, хəллəрем бик авыр...» ....................62
«Мин татар! — дип күкрəк суга...» ....................63
«Кибет алдында бер төркем» ....................64
«Нинди тавыш килə икəн, дисəм» ....................64
Ходай биргəн гомер ....................65
«Яңа гына яуган яшь карларга» ....................65
«Сез булганга җирдə яшəү» ....................66
Яшисем килə ....................67
«Гомеремнең яңа гына» ....................67
«Нəнəмнең бишек жыры» ....................68
Əрнү ....................69
«Əллə нигə мин үземне» ....................69
Мин табигать кочагында ....................70
«Кабер казырга кычкырып» ....................71
«Көтмəгəндə хəбəр булды...» ....................72
Буранлы көн ....................73
«Бүə елгасыннан бозлар китə...» ....................74
Яшик ....................75
«Кеше күңеле ватылырга торган» ....................75
Хастаханəдə ....................76
«Бер авылдаш килеп керде,» ....................77
Бүген бəйрəм ....................78
Түгелсен яшь ....................79
«Сорамыйм синнəн, сорамыйм...» ....................79
«Алмагачлар шау чəчəктə...» ....................80
Авылыма ....................81
Авылым турында ....................82
Бала күңеленең əрнүе ....................83-84
Уйланам ....................85
Рəхмəт ....................86
Чəчəкле яз килде ....................87

Казлар китә ....88
Кышкы ямь ....88
«Җәйнен нинди матур мәле...» ....89
Көчсез ....90
Монсуланма....90
Якташларга....91
Ял конендә....92
Хәйран калдым ....93
Шәһәрдән кайткан бер егеткә ....94
Көтмә ....94
Тәрбия ....95
Нотык....96
Теләгем ....97
Мондый үрнәк күрсәтмик ....98
«Авызында тәмәкесе...» ....98
Каенлыкта ....99
Гармун моңы....100
Үз фикерем ....101
«Кара икмәк ашамыйм мин...» ....102-103
Юл буенда чардуган ....104
«Бер ирне кулга алдылар» ....104
Авылдашым китте ....105
Көзге җыр ....106
Борчылам ....107
«Мин үскәч сугышка барам...» ....108
Чишмә буенда ....109
Күңел көрлеге....110
Тагын бер ятим ....110
Ике кошчык ....111
Минем бәхетем....112
Ялгыз ана....113
«Коляскама килеп тотынды да...» ....114
Юлга чыгам....115
Каз өмәсендә....115
Яңа ел иртәсе....116
Китмә, әнкәй! ....117
«Тәрәзәмә таш аталар...»....117
Ялгыз калгач ....118
Шатлык ....118
Горурланам....119
Чакыр мине ....120
Гомер телим ....121
Иртәнге җыр....121
Гашыйк егет җыры....122
Килер язлар бар әле....123
Туган җирдә калыйк....123
Кышкы кичтә....124
Язгы җыр....124
Син мине ярат әле....125
Әнкәйгә....126
Чәчәк бүләк итәм....126
Урамым ....127
Таш бәгырь....128
Бер аңлармы?....129
Беләсезме?....129
Егетлек! ....130
Татлыдан да татлы....130
Шигырь язам....131
Тере чишмә....132

Литературно-художественное издание

*Рафис Мухамматдинов*

# *Голос сердца моего*

**Стихи**

Редактор Ляля Ибатуллина.
Технический редактор
Дарвин Ибатуллин.

Формат А-5
Бумага офсетная.
Тираж 500 экз.

Отпечатано в ГУП «Татышлинская районная типография» РБ. 452830, Республика Башкортостан, с. В. Татышлы, ул. Ленина, 91.